4. Имеет ли мемориал реальное захоронение? похоронен ли кто-либо в могиле?
5. Когда отмечают день памяти Неизвестного солдата?
6. В каком году впервые отмечен день памяти неизвестного солдата?
7. С какого по какой год шла Великая Отечественная Война?
8. Какого числа произошло вторжение Германии в СССР?
9. Какой подвиг совершил Александр Матросов?
10. Назовите самое крупное танковое сражение в истории, имевшее место во время Великой Отечественной Войны?
11. Назовите мемориал и место где он установлен (по фотографии на экране, 4 фото)

Подведение итогов викторины

В заключение, на доброй ноте, совместное пение песни «Алеша». «Алёша» — советская песня Эдуарда Колмановского на стихи Константина Ваншенкина, посвящённая памятнику советскому солдату «Алёша» в болгарском городе Пловдиве как символу памяти всем советским солдатам, освобождавшим Болгарию от фашизма во Второй мировой войне.

Благодарность за память, уважение, почтение героев ВОВ!

Используемая литература

1. Артемов В.В. История: учебник для студентов учреждений СПО: в 2 ч. Ч. 2./ В.В. Артемов, Ю.Н. Лубченков. – 3-е изд., доп. – М.: Издательский центр «Академия», 2020. – 400 с.

2. История России для технических специальностей : учебник для среднего профессионального образования / М. Н. Зуев [и др.] ; под редакцией М. Н. Зуева, А. А. Чернобаева. — 4-е изд., перераб. и доп. — Москва : Издательство Юрайт, 2023. — 531 с. — (Профессиональное образование). — ISBN 978-5-534-10532-2. — Текст : электронный // ЭБС Юрайт [сайт]. — URL: biblio-online.ru/bcode/430762

Дополнительные источники:

3. Прядеин, В. С. История России в схемах, таблицах, терминах и тестах : учебное пособие для среднего профессионального образования / В. С. Прядеин ; под научной редакцией В. М. Кириллова. — Москва : Издательство Юрайт, 2019 ; Екатеринбург : Изд-во Урал. ун-та. — 198 с. — (Профессиональное образование). — ISBN 978-5-534-05440-8 (Издательство Юрайт). — ISBN 978-5-7996-1505-5 (Изд-во Урал. ун-та). — Текст : электронный // ЭБС Юрайт [сайт]. — URL: biblio-online.ru/bcode/441631

4. biblio-online.ru/bcode/430762

Йолдызлы капкалар. Сыйныф сәгате.

Татар мәктәбенең 2нче сыйныф укучылары өчен

Ахметшина Айгөл Фаукатовна,
Семенова Надежда Николаевна,
“Адымнар-Алабуга” күптелле белем бирү комплексы

Максат: укучыларга Бөек Ватан сугышы, сугыш чоры балалары, Бөек Җиңүгә 81 ел турында мәгълүмат бирү.

Бурычлар:

1.Белем бирү бурычы: сугыш, җиңү, сугыш чоры балаларының тормышы турында мәгълүмат бирү.

2. Үстерү бурычы: танып-белү активлыгын, күзәтү, чагыштыру, нәтиҗәләр ясый белүне үстерү, уку грамоталылыгын, сөйләм телен үстерү.

3. Тәрбияви: сугыш ветераннарына хөрмәт – ихтирам хисләре, кешелеклелек сыйфатлары тәрбияләү, ипине кадерләргә өндәү.

Җиһазлау: компьютер, презентация, видеоязма, аудиоязма, таратма материал, ике яклы өй макеты.

Дәрес барышы

I Оештыру. Уңай психологик халәт тудыру.

а) Уңай эмоциональ халәт булдыру

-Исәнмесез, укучылар! Хәерле көн! Кәефләрегез ничек?

II Мотивация.

1) Кереш әңгәмә.

-Укучылар, сез Казан шәһәрендә яшисез? Авылга кайтканыгыз бармы? Анда кемнәр яши? Сез әби-бабайларыгызны яратасызмы? Карагыз әле, биредә дә бер өй бар. Игътибар итегез әле, ул нинди? Бу кыз нинди? Ул ни өчен елмая?

2) Проблеманы кую.

-Игътибар белән экранга карагыз әле.

- Йорт нинди? Капкасына игътибар итегез әле, анда нәрсә күрәсез? (кызыл йолдыз)

-Сезнең йолдызлы капкалар күргәнегез бармы? Капкага йолдыз ни өчен куела икән?

3) Кечкенә хикәя-истәлек. Аудиоязма

-Укучылар, әйдәгез бергәләп бер язма тыңлап алыйк әле. АУДИО

Хәтерендә әле Гөлгенәнең, башлангыч сыйныфларда укып йөргәндә аларның капкаларына кызыл йолдыз кадаклап киттеләр! И сөенде инде кыз, болай да матур капкаларына тагын да нур өстәлгәндәй булды, әйтерсең лә күктән бер якты йолдыз аларның капкаларына төшеп кунды...

Ишетәсеңме, әткәй? Менә сине ничек зурладылар! Күкрәгеңдә бер йолдызың бар иде инде, менә икенче йолдызың да булды! Тик үзең генә, ***сугыштан*** *яраланып кайткач озак яши алмадың шул.*

Гөлгенәгә әтисе калдырган йолдызлы капкадан да кадерле әйбер юк иде!

4) Әңгәмә

- Гөлгенә ни өчен сөенә? Гөлгенәләрнең капкаларына нәрсә кадаклап киткәннәр?

-Гөлгенәнең әтисе кайда яраланган? (**сугышта)**

-Сезнеңчә, ни өчен Гөлгенәләрнең капкаларына кызыл йолдыз кадаклаганнар? (чөнки **сугышта** катнашкан)

5) Максат кую.

-Димәк, бүген нәрсә турында сөйләшәчәкбез? (Сугыш турында)

III Төп өлеш.

1) Бөек Ватан сугышы башлану турында мәгълүмат.

- Җәйге матур төн. Сызылып кына таң атып килә. Тирә-юньдә үзәкләрне өзәрдәй кошлар сайравы.

Ә шушы вакытта илебезгә фашистлар һөҗүм итә. (аудиоязма) Бу 1941 елның 22 июнь таңы. Бөек Ватан сугышы башлана.

2) Сугыш төшенчәсе турында мәгълүмат.

- Нәрсә соң ул сугыш?

-Сугыш дип әйтүгә, минем күз алдыма җимерелгән йортлар, актарылып беткән болыннар, ятим балалар килеп баса. (өйне, кызны әйләндерергә) Әйе, рәхимсез сугыш илебез халкына әйтеп бетергесез кайгы-хәсрәт китерә.

Укучылар, карагыз әле, сугыш башлангач, өй ничек үзгәрде? Ә кыз нинди? Ул ни өчен елый?

- Балалар, ә Бөек Ватан сугышы озак барганмы?

- Сугыш еллары бик авыр еллар була. Бу дүрт ел дәвамында күп шәһәрләр, авыллар, завод-фабрикалар җимерелә, бик күп кешеләрнең гомерләре өзелә.

Бирем:

-Укучылар, сезнең өстәлләрегездә конвертлар бар. Алар эченнән сүзләрне алыгыз да, сугыш темасына туры киләннәрен табыгыз һәм тактага беркетегез.

Сугыш - үлем, ут, яралар, күз яшьләре, кайгы, ачлык.

3) "Сугыш чоры балалары" турында мәгълүмат.

-Әйе, сугыш кешеләргә күп кайгы-хәсрәт китергән. Әтиләр һәм абыйлар сугышка киткәндә әниләр һәм балалар үзләре генә калган. Бөтен эшне алар башкарган.

-Нисек уйлыйсыз, сугыш чорында балалар нишләгән соң? Игътибар экранга

- Укучылар, балалар нишлиләр?

- Кечкенә балалар да, әниләре белән беррәтән басуда урак урганнар, заводларда эшләгәннәр. Бу елларда бик күп балалар ачлыкта яшиләр, ятим калалар.

-Ничек уйлыйсыз, балалар мәктәптә укыганнармы? Экрандагы рәсемдә сез кемнәрне күрәсез? (балалар, кара белән каләм) Алар нишлиләр? (укыйлар)

4) Истәлекләр. Аудиоязма

-Сугыш вакытында сезнең кебек 2нче сыйныф укучысы булган, бүгенге көндә авылда яшәүче бер әбинең истәлеген тыңлыйк әле. (аудио)

Иң үзәккә үткәне − сыйныф бүлмәсендәге салкынлык. Сыйныф бүлмәсен иртәнге якта салам белән генә җылыталар. Әлбәттә инде, без киез итек, бияләйләрдән утырдык. Уң кулга каләм, яза торган карабыз салкында туңмасын өчен, сулына кара савыты тота идек.

Мәктәптә иң яратканым — ул озын тәнәфес иде, чөнки безгә һәркайсыбзга 50 шәр грамм ипи тараталар. Аны укытучылар тактага куеп, тигез итеп кисә... Ул ипине авызга салудан да зур бәхет юк. Миңа исә кисәкне энем белән дә бүлешергә кирәк. Кисәкне тулысынча ашап бетерәсем бик килә, әмма әни бүлешергә кирәк дип аңлатта. Ул вакытта ук безнең арада ярдәмләшү, аңлашу хисе тәрбияләгән өчен әниемә рәхмәт.

-Балалар, 50 грамм икмәк ул күпме?

-Сезнеңчә, менә бу кисәк ипи белән тамак туярмы? (ипи күрсәтү)

-Әлбәттә, юк. Бүгенге көндә сезгә ашханәдә ипине үлчәп бирәләрме? Ни өчен? (юк, чөнки ул күп)

Сугыш чорында балалар кечкенә генә ипи кисәген дә бүлешеп ашаганнар. Ә сез бертуганнарыгыз, дусларыгыз, сыйныфташларыгыз белән ярдәмләшеп яшисезме? Сез дә шулай нәрсәләрне булса да бүлешәсезме? Бер-берегезгә ярдәм итәсезме?

-Без сезнең белән бүген бик бәхетле яшибез, ашау мул, бер телем ипи өчен тилмереп яшәмибез.. Ләкин ипи никадәр күп булса да, без аның кадерен белергә тиеш. Ипине бервакытта да ташларга, аның валчыгын да әрәм итәргә ярамый.

5) Кәрәз җыю. Сугыш чоры балалары

-Нәтиҗә ясыйк: сугыш чоры балалары

-Балалар нәрсә белән язганнар? (каләм, кара)

-Авылларда мәктәпләрне нәрсә белән җылытканнар? (мичкә ягып)

-Балалар кемнәргә булышканнар? (әниләренә)

-Балалар кайда эшләгәннәр? (кырларда, заводларда)

-Алар нинди булганнар? (тырыш)

-Баларның тамаклары тук булганмы? (ач)

Әйе, укучылар, сугыш вакытында балаларга да бик авыр булган, ләкин алар бирешмәгәннәр.

6) Җиңү көне турында

-Бу нинди күренеш? Нәрсә аңладыгыз? Бөек Ватан сугышы 1945 нче елның 9 нчы маена кадәр дәвам итә. Бу дәһшәтле сугышта безнең илебез җиңеп чыга.

Сугыш беткәч бар халык шатлана.

-Җиңү шатлыгын нинди сүзләр белән аңлатып була? Тактага алып чыгып беркетегез әле.

7) Җиңү төшенчәсе турында мәгълүмат.

(шатлык, елмаю, очрашу, күрешү, бәйрәм, җыр-бию)

Сугыш беткәч әкренләп яңа йортлар төзелә, шәһәр һәм авыллар төзекләнә.

IV Рефлексия

1945 елның 9 маенда зур бәйрәм булган. Шуннан бирле илебез ел саен Бөек Җиңү көнен билгеләп үтә.

- Укучылар, сез беләсезме, быел Бөек җиңүгә ничә ел тула? 81 ел

-Укучылар, сезнең бабаларыгызның бабалары Бөек Ватан сугышында катнашканмы?

- Мин сезгә китапчыклар бүләк итәм. Өегезгә кайткач, әти-әниләрегездән бабаларыгыз турында сорашыгыз. Бу китапчыкларга аларның исемнәрен язып куегыз, алар турында онытмагыз.

Бүгенге сыйныф сәгатендә катнашуыгыз өчен зур рәхмәт! Сау булыгыз!

Дети-герои нашего времени и их подвиги. Подвиги героев Великой Отечественной войны. Урок мужества.

Целевая аудитория: учащиеся 5 класса

Ахметшина Миляуша Гаптельбаровна,
учитель математики высшей
квалификационной категории
МБОУ «СОШ с. Манзарас»
Кукморского МР РТ

Цель: Воспитание чувства патриотизма, уважения к истории своей страны, формирование нравственных ценностей, таких как смелость, долг, честь, ответственность.

Задачи:

Познакомить учащихся с понятием "мужество" и его проявлениями.

Рассказать о героях прошлого и настоящего, чьи поступки стали примером мужества.

Обсудить, как проявлять мужество в повседневной жизни.

Способствовать развитию у учащихся способности анализировать, делать выводы и выражать свое мнение.

Создать атмосферу доверия и взаимного уважения.

Форма проведения: Беседа, рассказ, обсуждение, творческое задание.

Оборудование:

Мультимедийный проектор, экран.

Презентация с фотографиями и краткими биографиями героев.

Листы бумаги, цветные карандаши/фломастеры.

Тематическая музыка для фона.

Содержательный компонент классного часа

I. Вступительная часть.

II. Основное содержание: 1. Мозговой штурм. 2. Знакомство с примерами мужества 3.Значение мужества.4. Творческое задание: "Мой герой"

III. Заключительная часть.

Рефлексия: «Всё в наших руках!»

Ход классного часа:

I. Организационный момент (5 минут)

Приветствие.Создание позитивного настроя.

Объявление темы и целей классного часа.

Классный руководитель: Здравствуйте, ребята! Сегодня мы собрались, чтобы поговорить о чем-то очень важном, о том, что присуще каждому настоящему человеку, о том, что помогает преодолевать трудности и делать мир лучше. Мы поговорим о мужестве. Как вы думаете, что такое мужество?

II. Актуализация знаний и вводное слово (7 минут)

Мозговой штурм: Учащиеся высказывают свои идеи о том, что такое мужество. Классный руководитель записывает их на доске или на листе ватмана.

Классный руководитель: Отлично! Вы назвали много важных качеств: смелость, отвага, готовность защищать, не бояться. Давайте попробуем дать такое определение: Мужество – это не отсутствие страха, а способность преодолевать его, действовать решительно и правильно, даже когда страшно. Это готовность идти до конца ради правого дела, ради других людей.

Связь с повседневностью:

Классный руководитель: Ребята, а где и как мы можем проявить мужество в нашей обычной жизни, в школе, дома?

Примеры ответов: помочь слабому, уступить место старшему, признаться в ошибке, встать на защиту друга, не бояться высказывать свое мнение, когда оно отличается от мнения большинства, учить уроки, даже если это трудно.

Классный руководитель: Важно понимать, что мужество проявляется не только в героических поступках, но и в повседневной жизни. Даже маленький, но смелый поступок это уже проявление мужества.

III. Знакомство с примерами мужества (15 минут)

Рассказ классного руководителя с презентацией: классный руководитель рассказывает о примерах мужества из истории и современности.

Подвиг Данила Садыкова — 12-летнего подростка из города Набережные Челны, который погиб, спасая 9-летнего школьника. Трагедия произошла на бульваре Энтузиастов 5 мая 2012 года: у 9-летнего Андрея Чурбанова в фонтан упала пластиковая бутылка, при попытке её достать мальчика ударило током, вода оказалась под высоким напряжением. Он потерял сознание и упал в бассейн. В это время Данил Садыков проезжал мимо на велосипеде. Мальчик прыгнул в воду и сумел вытащить пострадавшего на бортик, однако сам получил сильный удар током. До приезда «скорой помощи» Данил умер, а спасённый мальчик остался жив. Данил Садыков посмертно награждён Орденом «За проявленное мужество и самоотверженность при спасении человека в экстремальных условиях».

Подвиг Лидии Пономарёвой — в июле 2013 года 12-летняя девочка спасла двух 7-летних детей, которые купались в реке. Опередив взрослых, Лида бросилась в реку на помощь тонущему мальчику, а потом вытащила и девочку, которую относило течением от берега. С берега в помощь Лиде бросили спасательный жилет, который помог ей дотянуть девочку до берега.

Подвиг Артёма Артюхина — ученик 9 класса спас из пожара ученицу из своей школы Олю Аксимову, за что был награждён медалью «За отвагу». В тот день он, возвращаясь домой, заметил горящее 10-этажное здание, из которого доносились крики о помощи. Артём бросился в горящее здание и на 8-м этаже нашёл девочку, звавшую на помощь. Выбив дверь в коридоре, Артём вывел девочку из горящего здания.

Поступок 7-летнего Вани Макарова — в октябре 2013 года Ваня со своей одноклассницей Женей играли на льду местной речки в Ивделе Свердловской области. Внезапно под Женей лёд проломился, и она в пуховике оказалась в ледяной воде. Ваня не растерялся, подполз к полынье, ухватился за портфель девочки, которая почти скрылась под водой, и с большим трудом ему удалось спасти девочку. Поступок Ивана Макарова отметили на областном уровне — губернатор вместе с начальником Главного управления МЧС региона наградили его медалью «За спасение погибающих на водах».

Подвиги героев Великой Отечественной войны.

Александр Матросов — закрыл собой амбразуру вражеского дзота, спасая товарищей.

Зоя Космодемьянская — партизанка, которая погибла от рук фашистов, не предав своих соратников.

Алексей Маресьев — лётчик, который после потери ног продолжил сражаться и сбивать врагов.

Николай Гастелло — направил свой горящий самолёт на вражескую колонну, совершив героический таран.

Василий Зайцев — легендарный снайпер, уничтоживший более 200 немецких солдат в битве за Сталинград.

Подвиг героев-панфиловцев в битве под Москвой (1941). Группа истребителей танков 316-й стрелковой дивизии (28 человек во главе с политруком Василием Клочковым) в течение четырёх часов под шквальным огнём артиллерии и бомбёжками с воздуха сдерживала танки и пехоту врага. Они отразили несколько атак противника и уничтожили 18 танков из 50, но большинство бойцов отряда погибли, остальные были тяжело ранены.

Обсуждение:

Вопросы для обсуждения:

Что вызвало у вас больше всего эмоций?

Почему этот человек поступил именно так?

Что им двигало?

Как вы думаете, было ли ему страшно?

Как мы можем назвать поступок этого человека?

IV. Значение мужества (7 минут)

Классный руководитель: Ребята, давайте попробуем понять, почему мужество так важно.

Обсуждение:

Без мужества трудно добиться чего-либо стоящего?

Мужественные люди могут вдохновлять других?

Мужество помогает бороться со злом?

Что бы было, если бы люди не были мужественными?

Учитель: Мужество – это не только личное качество, но и основа для сильного общества, для сильной страны. Когда люди готовы отстаивать свои ценности, защищать слабых, идти наперекор трудностям, они делают мир лучше.

V. Творческое задание: "Мой герой" (6 минут)

Учитель: А теперь давайте попробуем визуализировать мужество. Каждый из вас может представить себе героя. Это может быть историческая личность, герой книги, фильма, а может быть, кто-то из ваших близких, кто проявил себя смелым и решительным.

Задание: Возьмите лист бумаги и цветные карандаши. Нарисуйте вашего героя, или напишите письмо герою-2 предложения благодарности герою.

(Во время выполнения задания можно включить спокойную, воодушевляющую музыку.)

VI. Итоги классного часа (5 минут)

Обмен впечатлениями: желающиепоказывают свои рисунки и коротко рассказывают о своем герое и зачитывают письмо герою.

Рефлексия:

1. Какими качествами должен обладать герой?
2. Подвиг какого юного ребенка-героя вам особенно запомнился и почему?
3. Какие качества проявили наши герои? Кто может стать героем?

Классный руководитель: Сегодня мы говорили о мужестве. Это важное качество, которое помогает нам быть сильными, честными и благородными. Помните, что мужество живет в каждом из нас. Проявляйте его в добрых делах,

в помощи другим, в преодолении своих слабостей. И пусть ваши поступки всегда будут достойными! Спасибо за внимание!

Использованная литература:

1) Сайт «Достижения.рф.» https://xn--d1acchc3adyj9k.xn--p1ai/
2) Сайт «Музей Победы» https://victorymuseum.ru/
3) «Наши герои» https://razgovor-cdn.edsoo.ru/media/file/together-111-dop2.pdf

“За тебя, о родина моя, за большую правду умираю!” Урок мужества.

Целевая аудитория: учащиеся 5-9 классов

Бадертдинова Резеда Илдусовна,
МБОУ «Иляксазская ООШ»
Сармановский муниципальный район,РТ

Цель: воспитание патриотизма, гордости за свою Родину, любви к Отечеству через пример героической жизни М.Джалиля, уважение к героям Великой Отечественной войны.

Задачи:

- формирование понимания мужества, героизма, самоотверженности;
- ознакомление с жизнью и творчеством поэта;
- развитие интереса к истории своей страны и родного края.
- воспитание чувства благодарности и уважения к ветеранам войны.

Оборудование:

Портрет Мусы Джалиля.
Выставка книг, посвященных Мусе Джалилю.
Музыкальное сопровождение (песни, стихи).

Ход урока.

I. Организационный этап.

Приветствие участников, объявление цели и задач урока мужества.
Слово учителя:

-Мы сегодня с вами собрались поговорить о поэте-фронтовике, который, попав в плен, вел подпольную борьбу и принял героическую смерть, оставаясь верным Родине.

II. Основная часть

1. Рассказ учителя о жизни и творчестве Мусы Джалиля.

Учитель: Муса Джалиль родился в 1906 году в деревне Мустафино Оренбургской губернии в семье крестьянина Мустафы Залилова. В 6 лет он поступил в сельскую школу. В 1913-1922 гг. он учился в медресе «Хусаиния» в Оренбурге. Был очень любознательным, умным подростком. К десяти годам перечитал все книги в расположенной по соседству библиотеке «Белек». Поэт с детства проявлял интерес к литературе и искусству.

Его первые стихотворения были напечатаны в газете «Кызыл Йолдыз» в 1919 г., а потом в 1920 гг. – в журнале «Безнең юл» (ныне журнал «Казан

утлары»). После окончания рабфака в Казани Муса Джалиль поступил в Московский государственный университет и окончил его в 1931 году.

Он работал ответственным редактором в журнале «Кечкенә иптәшләр”, редактором – в пионерском журнале “Октябрь баласы”. У него было много друзей и товарищей среди писателей и поэтов. М. Джалиль активно работал в комитете ВЛКСМ. С 1929 г.- член коммунистической партии.

«…Молодости пыл
Я отдал дням, что в битвах закалялись.
Я созидал, и труд мне сладок был,
И замыслы мои осуществлялись».

- написал Муса Джалиль.

Началась Великая Отечественная война, Муса добровольцем ушел на фронт, стал старшим политруком и корреспондентом армейской газеты «Отвага». 1942 году был тяжело ранен и попал в плен.

«Прости меня, твоего рядового,
Самую малую часть твою,
Прости за то, что я не умер
Смертью солдата в жарком бою»,- написал поэт.

Муса показал настоящее мужество даже в неволе. Вел борьбу против фашистов в плену, организовал подпольную антифашистскую организацию. Готовил восстание военнопленных, но донос провокатора и арест сорвал эти планы.

Его книга стихов "Моабитская тетрадь" стала символом стойкости духа, верности Родине и любви к народу. За мужество и героизм, проявленные в годы войны, он удостоен звания Героя Советского Союза посмертно.

2. Чтение стихотворений Мусы Джалиля учениками

Чтение заранее подготовленных стихов («Красная ромашка», «Песня девушки», «Платочек», «Последняя песня», «Волки») ученикам класса.

Прослушивание песни «Җырларым”

3. Обсуждение прочитанного материала

Вопросы для обсуждения:

- Что вас впечатлило больше всего в произведениях Мусы Джалиля?
- Как вы понимаете смысл понятия "мужество"?
- Какие качества характера присущи настоящим героям?

4. Викторина по материалам урока

Проведение викторины среди учеников, проверяя знания о жизни и творчестве Мусы Джалиля.

Вопросы:

- Назовите родину Мусы Джалиля.
- Какой подвиг совершил поэт во время войны?
- Почему книга "Моабитская тетрадь" получила такое название?
- Отчего ромашка стала красной в стихотворении М.Джалиля?
- Кого он сравнивает волками в своём стихотворении «Волки»?
- Как зовут жену и дочь М.Джалиля?

III. Заключительная часть

Подведение итогов мероприятия, поощрение активных участников.

Учитель: Мы благодарны вам за участие в нашем мероприятии. Помните, что герои живут рядом с нами, каждый из нас может стать героем своего дела!

Исполнение песни учениками “Салют сиңа, Муса Җәлил”.

Без- Җәлил оныклары. Батырлык дәресе.

Башлангыч сыйныф укучылары

Борһанова Гөлфинур Галимҗан кызы,
Сафиуллина Рәсимә Рамил кызы,
ТР Нурлат районы МБГБУ “Колбай Мораса УГБМ”

Максат: укучыларны Муса Җәлилнең тормыш юлы, ижаты һәм сугышта күрсәткән батырлыклары, Җәлилчеләр белән таныштыру. Муса Җәлил шәхесе һәм Җәлилчеләр белән горурлану, соклану хисләре тәрбияләү. Сөйләм телен үстерү,баету.

Бурычлар: Укучыларны Муса Җәлилнең шигырьләрен сәнгатьле сөйләргә өйрәтү. Муса Җәлил тормышына һәм ижатына кызыксыну уяту. М.Җәлилнең ижатын һәм тормыш юлын тирәнтен өйрәнү.

Зал бизәлеше: Дәрес буласы сыйныф бәйрәмчә бизәлә. Түрдә Муса Җәлилнең портреты һәм китаплар күргәзмәсе , Җәлилчеләргә багышланган стенд, плакатлар эленгән.

Дәрес “Бөек шагыйрь Муса Җәлил “җыры белән башлана (укучылар җырлый)

1нче укучы: Хәтерләүдән курыкма син!

Батырларны онытма син!

2 нче укучы: Без-Җәлил оныклары.

3 нче укучы: Әй, шагыйрләр!

Зур сугышның кайтавазы булып,

Яңгырасын үлмәс җырыгыз!

4нче укучы: Һәрвакыт булсын кояш!

Һәрвакыт булсын һава!

Һәрвакыт булсын әни!

Һәрвакыт булыйм мин!

1нче укытучы:

-Хәерле көн кадерле укучылар,кунаклар! Бүген без сезнең белән герой шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган “Без -Җәлил оныклары” дип исемләнгән дәрескә җыелдык.

Муса Җәлил... Бу исем һәркемгә яхшы таныш. Шагыйрь, сугышчы, көрәшче. Бөек Ватан сугышы каһарманы. Ул 1906 елның 15нче февралендә Оренбург өлкәсендә туа. Кечкенәдән үк әдәбият белән кызыксына. “Бәхет” исемле берен- че шигыре “Кызыл Йолдыз” газетасында басыла. Мусага ул вакытта 13 яшь бу-ла. 1922 елда ул Казанга килә. Укырга керә. Аннары Мәскәүдә “Кечкенә иптәшләр “ дигән балалар журналы редакциясендә җаваплы редактор

булып эшли ашлый. Бик күп шигырьләр яза. Гитлерчылар белән сугыш башлангач, Муса Җәлил фронтка китә.

5 нче укучы: Илем! Алдыңда синең мин ант итәм
Шаһит булсын кулым ярасы.
Гитлер явын тар-мар итми торып
Якты күрмәс күзем карасы.

2 нче укытучы: Әдип бер минут вакытын да әрәм итми дошманга каршы корал белән дә, ялкынлы шигырьләре белән дә көрәшә.

“Салют сиңа Муса Җәлил” җыры (укучылар җырлый)

1нче укытучы: 1942 елда ул әсирлеккә төшә-фашистлар кулына эләгә. Җәлил һәм аның иптәшләре тоткынлыкта да дошманга каршы көрәшәләр. Гитлерчылар моны белеп алып, аларны җәзага тарта. Муса Җәлил белән аның ун көрәштәше дә үлем җәзасына хөкем ителә. Аларның исемнәрен хәтеребездә тотыйк! (*Интерактив тактада шигырьләр тәртибендә Җәлилчеләрнең сурәтләре күрсәтелеп барыла)*

1нче укучы: Муса абый ялгыз түгел,-
Иптәшләре бар ич:
Бер иптәше -әкиятче
Абдулла Алиш .

2 нче укучы: Син халкымның батыр улы,
Исемең мәңге онытылмас:
Һәрчак безнең йөрәктә син-
Гайнан абый Кормаш!

3 нче укучы: Батырларны барлыйм, дисәң,
Тарих дәфтәрләрен актар:
Шундый батырларның берсе-
Абдулла абый Симай !

4 нче укучы: Батырлар турында һәркөн
Шигырьләр, җырлар туа...
Җыр улып яши күңелдә
Хәсәнов Зиннәтулла!

5 нче укучы: Кайчандыр безнең шикелле
Булгандыр ул бер сабый...
Һәрчак безнең күңелдә син-
Шабаев Гариф абый!

6 нчы укучы: Дошманга каршы батырлар
Көрәшкәннәр берләшеп.
Ул батырларның берсе син-
Әхмәд абый Әднәшев!

7 нче укучы: Исемнәре мәңге балкый
Якты йолдызлар кебек.
Кыю иптәш һәм көрәштәш
Фәрит абый Сәйфелмөлек.

8 нче укучы: Көннәр матур,ак кар ява,

Күңелдә дәрт уятып ...
Тынычлык өчен көрәшкән
Фоат абый Булатов!
9 нчы укучы: Ил-Ватанга ант итә
Газиз халкым уллары...
Антыңа тугры калдың син-
Сәлим абый Бохаров!
10 нчы укучы: Дошман кулында булса да
Баш имәгән ул аңа.
Авырлыкларга да түзгән
Абдулла абый Баттал!

2 нче укытучы: Безгә тынычлык бүләк иткән Җәлилчеләрне, Җәлил абыйны онытмыйк! Шундый катлаулы шартларда да Җәлил үзенең кулыннан каләмен төшермәгән, бик күп әсәрләр иҗат иткән. Әйдәгез әле шулаарны тыңлап узыйк.

Укучылар М. Җәлил шигырьләрен сөйлиләр.

1нче укучы: Карак песи
Чоландагы ак майга
Ияләшкән күселәр,
Мин чоланны сакларга
Куштым ала песигә:
— Мияу, мияу, пескәем!
Барчы, зинһар, чоланга,
Майны сакла күседән,
Оясыннан чыгарма!
Песи күргәч күселәр
Койрыкларын кыстылар.
Йөрмәделәр чабышып,
Ярыкларга постылар.
Мияу, мияу, пескәем!
Колак салдың сүземә!
Каравылдан бушагач,
Сөт бирермен үзеңә!
Иртә белән майга дип
Керсәм, күзем акайды:
Явыз песи берүзе
Ялт иттергән ак майны!
— Мияу, мияу, пескәем,
Хыянәтче икәнсең.
Саклый торган маеңны
Үзең ашап киткәнсең!

2 нче укучы: Күке
Калын урманда, гел кичкә каршы,
Ишетелә моңлы бер кош тавышы

- Кәккүк, кәккүк, кәккүк!
Ул салмак кына кабатлый шуны,
Шул аның җыры, шул аның моңы:
- Кәккүк, кәккүк, кәккүк!
Ул ялгыз яши, чыгармый бала.
Менә шунлыктан ямансу аңа:
- Кәккүк, кәккүк, кәккүк!

3 нче укучы: Сәгать

Сәгать суга: «даң, даң!..»
Хәбәр бирә таңнан:
Мәктәпкә барырга
Унбиш минут калган.
Сикереп торды Марат,
Күрә — эшләр харап.
Тагын соңга калган,
Шул йокыга карап.
Сәгать йөри: «келт, келт!..»
— Тиз мәктәпкә кит, кит!..
Марат аңа дәшә:
— Тукта, мине көт, көт!..
Сәгать җырлый: «диң, диң!..»
— Мин бит туктый белмим.
Моннан ары: «зиң, зиң!»
Миңа карап йөр син!..

4 нче укучы: Кызыма

Шаян кызым син минем,
Таң йолдызым син минем,
Йөрәгемдә кабынган
Шатлык җырым син минем.
Синең гомерең җыр булып
Яңгырар бәхет илендә,
Йолдыз булып янарсын
Син туган ил күгендә.
Таңнан торып бакчада
Син уйнадың көнозын.
Аргансыңдыр, кил, кызым,
Йокла инде, йолдызым

5 нче укучы: Җәлил абый шигырьләрен
Бик яратып укыйбыз.
Сугыштагы батырлыгын
Үрнәк итеп сөйлибез.

6 нчы укучы: Муса абый,сине һәрчак
Хәтерләрдә сакларбыз.

Курку белмәс,шигъри җанлы
Син шагыйрь абыебыз!
Син батыр абыебыз!
Бергә: Хәтерләүдән курыкма син!
Батырларны онытма син!
Кызыл ромашка шигырен сәхнәләштерү белән дәвам ителә.
Катнашалар : 1 нче ромашка, 2 нче ромашка,3 нче ромашка, кызыл ромашка , солдат.
(Салмак кына көй. Таң ата. Ромашкалар уяна).
1 нче ромашка:
Хәерле иртә туганнар!
Хәерле иртә, кояш !
Сезне янә күрүемә
Мин, дусларым, бик тә шат!
2 нче ромашка:
Хәерле иртә, табигать!
Хәерле иртә, кошлар
Назлап исә таң җилләре
Чык сулары ап-ак саф.
3 нче ромашка:
Чү, дусларым! Ни күрәм!
Бу ни бу, ой, үләм?!
Әйт, сеңелкәй, ни булды?
Кемнәр каннарын койды?
1нче ромашка:
Ап-ак синең тажларың.
Ни өчен соң алландың?
Әллә берәр явызы
Берәрсен яралады?
2 нче ромашка:
Я, сеңелкәй,ач серең,
Сөйлә безгә син барын.
Ни өчен ак чукларың,
Синең бүген ал канлы.
3 нче ромашка:
Син, сеңелкәй ..
Ник үзгәрдең? Нишләдең?
Нидән кызыл чукларың,
Нидән алсу төсләрең?
Кызыл ромашка:
Төнлә минем яныма
Ятып атыр сугышчы
Атты дошманнарына .
Ул бер үзе сугышты

Унбиш укчыга каршы;
Чигенмәде, тик таңда
Яраланды кулбашы.
(Кызыл ромашка сөйләгән вакытта инерактив тактада сугыш сюжетлары күрсәтелә).

Кызыл ромашка:
Аның батыр ал каны
Тамды минем чукларга.
Минем кызыл күлмәгем
Бик ошады Чулпанга.
(“Каз канаты” көенә ромашкалар бию бии)

1нче ромашка:
Сугыш,сугыш кирәк түгел,
Кирәк түгел беркемгә.
Тыныч булсын, имин булсын,
Күкләребез гомергә.

2 нче ромашка:
Ак таҗларың алсуланды
Ал төс алды гомергә.
Яшә хәзер, көтеп син,
Батыр егетне гомергә.

Кызыл ромашка:
Егет китте,ә мин калдым ,
Канын саклап чугымда.
Көндә аны мин сагынып
Балкыймын таң нурында.

3 нче ромашка:
Сеңелкәем ,син борчылма,
Килер батыр сугышчы.
Алыр сине кочагына,
Боекма син, елмайчы.
(Тыныч кына, салмак көйгә кул , башын бәйләгән, ә икенче кулына байрак тоткан солдат керә)

Солдат:
Ерак илләр, ерак җирләрдән
Алып кайттым җиңү байрагын.
Илем өчен, туган җирем өчен,
Җиңеп чыктым дошман капкынын.
Шушы алан шаһит булды төнлә
Дошман белән минем сугышта.
Минем сөйгән алсу ромашкам,
Я, кайда син, кайда, кайда?
(Кызыл ромашка белән солдат биюе)

1нче укытучы:

Укучылар, шундый матур, тыныч тормышта яшәвебез белән без Муса Җәлил кебек шагыйрьләргә, Җәлилчеләргә, кадерле ветераннарыбызга бурычлы.

Безнең теләк бер: илләр, көннәр тыныч, күгебез аяз, һәркем бәхетле, шат булсын! Сугышлар булмасын!

Буыннар хэтере. Батырлык дәресе (квест-уен).

Максатчан аудитория һөнәри белем бирү оешмаларының 1-2 курс студентлары

Борһанова Дилә Мөҗәхит кызы,
Осипова Әлфия Баязит кызы,
ДАҺБУ "Лениногорск нефть техникумы"

Максатлар:

- үзенең кече Ватанына, туган иленә, һәм Россиянең күпмилләтле халкына, аның традицияләренә тирән бәйлелек хисе формалаштыру;
- Россиянең һәм аның мәдәниятенең казанышлары өчен горурлык хисе, Туган ил һәм үз халкының мәнфәгатьләрен яклау теләге. Ватанны саклауга әзер булучы тәрбияләү.

Бурычлар:

1. Сугыш чоры кешеләренең җиңүгә булган ышанычын, батырлыгын, рухи ныклыгын аңлату. Сугыш һәм тыл ветераннарына олы хөрмәт уяту
2. Буыннар арасында бәйләнешне ныгыту
3. Бөек Ватан сугышы турында белемнәрне барлау

КВЕСТ - УЕННЫҢ БАРЫШЫ

Укытучының кереш сүзе: Бөек җиңүне яулаганга 80 ел якынлаша, Бик күп еллар үтелгән, чор белән чор алышынган, тик ничек кенә булмасын, без халкыбызның тарихын, үткәнен онытырга хаклы түгелбез. Үзенең тарихын белмәгән кеше, киләчәге турында уйланмый.Безнең өчен Бөек Ватан сугышы ерак тарих,ләкин без җиңүнең нинди корбаннар хакына яулап алынуын беркайчан да онытырга тиеш түгелбез.Бүген- һәркайсыбызның күңеле бер уй, бер теләк белән сугарылган: Туган илебез туфрагын дошман танклары таптамасын,күкләребез гел аяз, ил-көннәребез имин булсын.

Бүгенге сыйныф сәгатебез квест –уен формасында узачак. Уенда 4 команда катнаша,һәр командада унар студент, һәр команда үзенең маршрут кәгазе нигезендә хәрәкәт итә һәм 4 бирем үти:

Биремнәрне сез алдан ук алдыгыз, тикшеренү эше әзер,җырларга репетиция ясалган. Һәр өстәлдә 4 маршрут кәгазе.Җирәбә нәтиҗәсе буенча һәр команда үзенең маршрут кәгазен ала. Һәр тукталышта дөрес җавап өчен пазл элементы бирелә,нәтиҗәдә бу пазллар бер зур картинага зверелергә тиеш.

БЕРЕНЧЕ БИРЕМ: ӨЧПОЧМАКЛЫ ХАТЛАР НИ СӨЙЛИ.-СОЛДАТ ХАТЛАРЫН САҢГАТЬЛЕ ИТЕП УКУ

Фронт хатлары – Бөек Ватан сугышының ветераннары белән бергә бүгенге көнгә кадәр яшәп килгән тере шаһитлары, шул еллар фажигасенең көзгесе [1].

НӘБИУЛЛИН ФӘТТАХЕТДИН НӘБИУЛЛА УЛЫ

Сөекле симияләрем! Сезгә исәнлек хаты.

Бәгърем, күз алмам Рәхимә! Сиңа әйтәм шуны: оланнарны, зинһар, какма, ничек тә тәрбия итәргә тырыш. Аллага шөкер бит, безнең илдә тыныч бит әле

хәзергә. Сыер исән-сау булса, боерган булса, балаларга җитәр әле. Пусть, түләсе бар дип, аларны тилмертеп торма, ашат. Алар хәзер син эшкә җөргәндә өй саклый торганнардыр инде. Әлфия бик ябыкмадымы? Фәрди тазарып җиттеме инде? Син Әгерҗедән кайткач бик еламадылармы? Хат салган чагында кәгазь салырга тырыш, монда юк. Аннан соң хатны тиздән язып салыгыз. Менә минем монда язган сүзләрне онытма. Аннан соң кеше арасында яхшы йөр! Эшкә йөргәндә кеше белән сүзгә килеп йөрмә, кеше көлмәсен. Кеше арасында көлкегә калма, ярыймы! Монда сүз ишетелмәсен. 1941 ел, 20 август.

ЗАЛАКАЕВ ИСХАК ШӘРӘКЫЙ УЛЫ

Сагынычлы хат башы. Исәнмесез, кадерле әти һәм дә әнигә бик сагынып, бер күрергә зар булып, бик күп санда булган сәламнәремне сезгә кайтып ирешүен теләп сагыну хисе белән ышанып калам.

Мин әти һәм дә әни өйдә вакытта армиягә алынуымны, елларның ничек икәнен белә торып та, яшьлек белән сезгә бернинди дә ярдәм итәлмәдем. Армиягә китү күрше авылга китеп кайту иттереп уйланылган. Шулай да мин сездән сорыйм миннән кимчелек уйламавыгызны. Мин сезнең хезмәтегезне үлгәндә дә онытачак түгел. Киләчәк көндә исән-сау әйләнеп кайтып, бергә шатлыклы гомер кичерергә ходай язсын иде. Әни минем өчен елый торгандыр инде. Ничек кенә уйласам да, күз алдыма килеп тора. Мин әтине дә армиягә алганнардыр, дип уйлый идем. Инде Зиак әзи сезнең турыда бернәрсә дә язмаса да, исәнлегегезне белеп, шатлыгым эчемә сыймады. Әти дә өйдә икән әле, мин мондагы чамага чагыштырдым. Миннән хат сирәк алабыз дигәнсез, госпитальдә вакытта көн дә диярлек хат язып тордым. 10 нчы майда язган хатыгызны 10 нчы июньдә алдым. 1942 ел, 11 июнь.

ВӘЛИЕВ БАРИ КАДЫЙР УЛЫ

Исәнмесез! Сез ки якын булган әткәй белән әнкәйгә улыгыз Баридан бик сагынып, бер күреп туйганчы сөйләшәселәрем килеп, бик күптин күп сәлам. Мин сезгә барын да язып хат салган идем, алгансыз. Сезгә генә түгел, авылга бик күп кешегә салган идем. Берсенә бармаса, берсенә баргандыр. Шушы атнада без фронтка керәбез. Ниләр булыр. Без берни уйлаган юк. Кызык төсле. Көләбез дә, сөйләшәбез дә, авылны да искә төшерәбез. Киткәндә өстәл өстендә калган катык та искә кереп чыга. Алдагы көндә 1942нче елны сугышны бетереп, шатлык белән кайтабыз төсле. Аларны да уйлыйбыз.

Ашау ягы көнгә 650 грамм 3 аш. Хәзергә 500 сум акча да бар әле. Минашау ягына аптыраган юк. 650 граммны 65–70 сумга сатып алып була. Килү белән бөтен икмәкне сатып акча итеп куйган идем, итү (юкса – иск.) икмәкне урлыйлар. Мин алдатмадым анысы белән. Хәзер кирәк вакыт яңадан-яңа икмәк алып кына торам.

Башка Татарстаннан бер кеше дә юк. Бар да үзбәк, кыргыз, казакъ, тажик һәм ике урыс бар– вәт инде минем иптәшләр. Минем өчен кайгырмагыз, мин әлегә кадәр бернинди кыенлык күрмәдем. Ярый, барын да язмам, кәгазь җитми. Белеп булмый, бәлкем, кайтсам барын да сөйләрмен. 1942 ел, 12 июль.

ГОСМАН ФӘТХУЛЛА УЛЫ

Афзал дус! Якын дус итеп күреп, җылы язылган хатларыңмиңа яңа көч, яңа дәрт кертә Дус-ишләрдән бик аерым яшим мин, татарлар бөтенләй юк диярлек (бер татар егете бар, ләкин ул әдәби хезмәттән ерак кеше), шуңа күрәфикер алышып, әдәби эшләр өстендәэшләүтурында гәпләшеп утырырлык кешеләр гомумән биредәюк. Кайчакта иске иптәшләрне күрүөчен әлләкайларга барасы килә.

Афзал дус, бәлки, исән калсам, очрашырбыз. Әгәр мин сугыш кырларында ятып калсам, минем үтенеч: минем басылган һәм басылмаган әйберләрне карап чыгып (билгеле, төзәтүкертүкирәк булыр) балалар өчен бер җыентык кебек нәрсәоештыруда инициатива күрсәтсәңиде. Бу - кечкенәгенәбулса да, мин яратып эшләгән балалар өчен, яшь буын өчен миннән бер кечкенәгенә истәлек булыр иде…

Их, Афзал дус, белсәңиде, яшисе килә Менәбез торган хуторның исән калган чия агачлары хәзер ап—ак чәчәк җибәрде, һәр якта яшеллек, табигать үзенекен итә гамьсез кошлар сайрый, тирәюньгәямь кертә Ләкин бу күренешнеңямен кинәт туп тавышлары, баш очыннан очып киткән пуля сызгырулары гына боза. Дошманга каршы нәфрәт уяна, аны изеп ташлыйсы килә Афзал дус, син минем табигатемне беләсең элек тәмин кеше үтерүтүгел, тычкан үтерүгәдәкулым бармый иде. Әхәзер немец кабахәтләрен өере белән кырып ташлыйбыз, моны, теңкәгәтигән озынборын-черкине сытып ташлагандагы булган бер ләззәт белән эшлибез. Аларныңүлек гәүдәләре аркылы атлап алга барганда төкереп үтәбез.

Болар турында язмасам да, син аңлыйсыңинде, яза башлагач, тыйнаксыз каләм барын да яза бирде… Җитәр, землянканы караңгылык басты, күзләр начар күрә. Афзал дус, кулыңны кысып сәлам белән калам. 1944 ел 16май.

ИКЕНЧЕ БИРЕМ. СОЛДАТ ЙӨРӘГЕН ҖЫЛЫТКАН ҖЫРЛАР

Җыр көрәштә бик көчле корал булып торган,һәркемнең йөрәгенә үтеп кереп,җиңүнең безнең якта булачагына ышаныч уяткан,солдатларның рухын күтәргән. Җырлар җырлап утка кергән солдатлар [2].

Син кайтмадың

Сәхаб Урайский сүзләре, Мансур Мозаффаров көе

Бакчаларда гөлләр чәчәк атты,
Тормышыбыз кебек ямьләнеп.
Урман күлләренә аккош кайтты,
Сандугачлар килде әйләнеп.
Сандугачлар килде, аккош кайтты,
Син кайтмадың киткән җиреңнән.
Аккош китәр урман күлләреннән,
Син китмәссең минем күңелемнән.

«Җил йөри курганнар артында...»

Солдатлар Роберт Әхмәтҗанов сүзләре Фәтхерахман Әхмәдиев көе

Озатып, вокзаллар каршында
маңгайдан үптеләр аналар.
Тузанлы юллардан үттеләр
дөньяны күрмәгән балалар.
Балалар керделәр утларга,
балалар сүз бирде тупларга.
Күпләре, төренеп шинельгә,
калдылар ераста йокларга...

Әйләнеп кайтыгыз

Мансур Шиһапов сүзләре, Рим Хәсәнов көе

Агыла тын гына,
Җыр булып моң гына,
Кемнәрдер кайларга китәләр…
Сагыштан янганнар,
Яшьләре тамганнар
Юлларда өзелеп көтәләр.
Күңелдә йөргән яр,
Төшләргә кергән яр,
Кайсыбыз сагынмый, әйтегез?!
Яшьлекнең таңына,
Вәгъдәләр хакына
Тизрәк әйләнеп кайтыгыз.

Кайту

Марсель Галиев сүзләре, Луиза Батыр-Болгари көе Олы юлдан яуга киткән чакта

Таң җиленнән томан таралды.
Авыл башындагы куш наратка
Атлар да бит борылып карады.
Һаваларда торна тавышлары,
Ишетелә канат кагышлары.
Кошларда да кеше язмышлары,
Чит җирләргә китеп барышлары.

ӨЧЕНЧЕ БИРЕМ: ВИКТОРИНА

Викторина сорауларына онлайн форматта җавап бирү.

Сугыш турында без нәрсә беләбез?

Викторина сорауларына ссылка **https://quick.apkpro.ru/poll/116448**





ДҮРТЕНЧЕ БИРЕМ: ТАТАРЫСТАНЛЫЛАР - СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЙЛАРЫ

Командалар үз төбәкләренең Бөек Ватан сугышында катнашып Советлар Союзы герое исеменә лаек булган якташларыбыз турында сөйли.(Эзләнү-тикшеренү эшләреннән-.өзекләр).

Газинур Гафиятуллин-Советла Союзы герое исеме 1944 елның 3- июнендә бирелә. Лениногорс районы Сугышлы авылында туган. 1944 елның 14 январенда 20 нче полк Овсище авылын алырга дигән приказ ала.

Гафиятуллин отделениясендәге солдатлар беренче булып дошман траншеяларына үтеп керәләр, бик күп фашистларны юкка чыгаралар.

Ләкин дзот җимерекләре арасында бер пулемет атуын туктатмый. Газинур алга, пулеметка таба омтыла һәм амбразураны үз тәне белән каплый.

Әхмәдуллин Мутык Әхмәтҗан улы.

Әхмәдуллин Мутык Дунай елгасын (Венгрия) кичү вакытында аерылып тора. 1944 елның 4 декабреннән 5 декабрьгә каршы төндә, дошман артиллерия утына карамастан, ул көймәдә Будапешт янындагы Эрчи шәһәре районындагы 18 сугышчыдан десант җибәрә.

Елга аша чыккач, сержант дошман позицияләрен штурмлауда катнаша һәм беренчеләрдән булып дошман тылына һөҗүм итә.

Садриев Сәлах улы Саматов

1920 елда Иске Шөгер авылында туа. 1943 елның 24 сентябренә каршы төндә сержант Садриев җитәкчелегендәге отделение Хутор-Хмельная авылы (Черкасск өлкәсе) янында яшерен рәвештә Днепрны кичеп чыга, ләкин яр буенда дошманның көчле автомат уты белән очраша.Садриев алда дошманның безнекеләргә ата торган пулеметын күрә. Ул үзенең сугышчылары белән пулемет расчетының тылына чыга һәм аны юк итә. Советлар Союзы Герое исеме Самат Сәлах улына 1944 елның 3 июнендә бирелә.

Габдрәшитов Фазулла Габдулла улы

1943елның июнендә дошманның көчле артиллерия һәм пулемет уты астында Ф.Г Габдәшитов штурм групасы составинда беренче булып Гомель өлкәсенең Бригин районы Нивки авылы янында Днепр елгасын кичә һәм пулемет уты белән дошманны ярдан читкә алып ташлый.

1944 елның 15 гыйнварында.Габдрәшитов Фазулла Гфбдулла улына Советлар Союзы Герое исеме бирелә.





ПАЗЛ ЭЛЕМЕНТЛАРЫННАН “ВАТАН-АНА” ҺӘЙКӘЛЕН ҖЫЮ

Пазл элементлары җыелып, “Ватан-ана” һәйкәленең зур картинасына эверелде

МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ КИЛӘЧӘК БУЫННАРГА МӨРӘҖӘГАТЕ

Хөрмәтле студентлар, бүген безгә кунакка Муса абыегыз Җәлилов та килгән, һәм аның сезгә әйтәсе сүзе бар (ясалма интеллект).

https://disk.yandex.ru/i/TCdGNQc_MeAfiA



УЕНГА НӘТИҖӘ ЯСАУ:

1.Сезгә бүгеге сыйныф сәгате ошадымы?

2.Сезгә нәрсә күбрәк ошады?

3.Сез бүген нәрсәләр белдегез?

4. Сездә нәрсә горурлык хисе уятты?

5. Ничек уйлыйсыз сыйныф сәгате файдалы булдымы?

Әйдәгез сыйныф сәгатен "Җиңү көне"жыры белән тәмамлыйбыз.

Җиңү көне

Җиңү көне, ул бик еракта иде,
Тик өмет күмердәй сыкрап сүнмәде.
Утлы көлдән калкып кабындык кына,
Бу көнне без якынайту хакына.
Кушымта:Бөек җиңү көне, җанда чаткысы,
Бөек бәйрәм, чал чәчләрдә яктысы,
Бөек шатлык, күзләрдә яшж тамчысы
Җиңү көне, Җиңү көне, Җиңү көне
Көн һәм төннәр мартен миче тынмады,
Ватан-Ана керфеген дә йоммады,
Көн һәм төннәр антны ныгытты гына,
Бу көнне без якынайту хакына.
Саумы, әнкәй, кайталмады күбебез,
Ялантәпи чык ярмабыз инде без,
Җәяү җиттек җирнең җиде чатына
Бу көнне без якынайту хакына.

ӘДӘБИЯТ

1. «Татарстан» электрон иҗтимагый-сәяси басма. Электрон ресурс https://protatarstan.ru/news/dobroe-tat/front-hatlary

2. Ханипова И.И. Великая Отечественная война в памяти народа: потенциал источников личного происхождения и материалов устной истории // Историческая этнология. 2021. №1. URL: https://cyberleninka.ru/article/n/velikaya-otechestvennaya-voyna-v-pamyati-naroda-potentsial-istochnikov-lichnogo-proishozhdeniya-i-materialov-ustnoy-istorii (дата обращения: 14.04.2025

Ватанпәрвәр Рүзәл Минһаҗев – күпкырлы шәхес!

1-2 **т**өркем укучылары өчен батырлык дәресе

Бубекова Ильмира Әзһәм кызы,
Имаметдинова Рәсимә Галиәскәр кызы,
ДАһБУ «Муса Җәлил исемендәге
Минзәлә педагогия көллияте»

Максат: Ватанпәрвәр Рүзәл Минһаҗев шәхесе белән танышу.

Бурычлар:

- Рүзәл Минһаҗевның купкырлы шәхес булуын ачыклау;
- игътибарлык һәм сөйләм күнекмәләрен камилләштерү;

- ватанны яратырга, кешеләргә ярдәм итәргә, туган илгә, туган туфракка тугры булырга өйрәтү.

Парлы эш: Ватан һәм Ватанпәрвәр сүзләренә синонимнар табу.

Укытучы сүзе:

Мөслим районың горурлыгы, якты йолдызы – Рүзәл Минһаҗев Радик улы Метрәй авылыннан. Ул бүгенге катлаулы заманда, ватаныбыз авырлыклар кичергән чагында, чын мәгънәсендә батырлык үрнәге күрсәтеп яши. Аның һәр адымы, һәр фигыле ватанпәрвәрлекнең, кешелеклелекнең, ныклы рухның ачык чагылышы булып тора. Рүзәлнең батыр йөрәгендәге ватанга булган сөю, милләткә булган кайгырту һәркемгә үрнәк булырлык.

Группада эш: һәр группа текстны укый, аннан ижади рәвештә материал белән таныштыра (таратма материал: А3 бите, төсле карандашлар, фломастер, фотолар, кайчы, клей).

1 группа. Махсус хәрби операция башланганнан бирле Рүзәл бер минут та тыныч тормый. Аның йөрәге һәрдаим хәрби зонадагы егетләребез өчен җан ата. Аларның һәрберсенә авырлыкта терәк булырга, ярдәм кулы сузарга омтыла. Ул үзенең фикердәшләре белән утыз тапкыр махсус хәрби операция зонасына гуманитар ярдәм илтеп кайтткан. Һәрбер сәфәр – үзенә күрә бер батырлык, бер сынау. Чөнки юллар ерак, шартлар катлаулы, куркынычлар да юк түгел. Ләкин аның күңелендә бер генә максат: авырлыкта калган ватаныбызны саклаучы егетләребезгә ярдәм итү, аларның рухын күтәрү, аларга туган якның җылысын, кайгыртуын тоярга булышу. Бу гамәлләр аның чын мәгънәсендәге гражданин булуын, иленә, халкына тугрылыклы булуын раслый.

Һәр сәфәр алдыннан зур әзерлек бара. Азык-төлек, кием-салым, дарулар, җиһазлар – иң кирәкле әйберләр җыела. Рүзәл Минһаҗев боларның барысын да жыюны оештыра, туплый, юлга әзерли. Аның бу эшне башкаруында һәрвакыт зур җаваплылык, тәртип, төгәллек сизелә, чөнки белә: ул оештырган һәр ярдәм, һәр бүләк егетләребез өчен бик кадерле. Бу бит гади генә посылка түгел, бу – туган яктан килгән хәбәр, туган йорттан килгән җылылык, әти-әниләрнең, хатыннарның, балаларның, туганнарның мәхәббәте һәм догасы. Рүзәл егетләр дип җан ата. Ул аларны бары тик солдатлар гына дип түгел, ә үз туганнары кебек кабул итә. Аларның һәрберсенең сау-сәламәт кире кайтуы аның өчен иң зур теләк. Һәр барганында ул алар белән аралаша, сөйләшә, аларның күңелләрен күтәрә, аларның ихтыяҗларын тыңлый. Аларның күзләрендәге өметне, ныклыкны, кайвакыт сагышны да күрә һәм шушы очрашулардан илһамланып, тагын да зуррак көч белән эшли башлый. Ул егетләргә туган якта аларны көтүләрен, алар белән горурлануларын җиткерә, бу исә солдатларның рухын, көрәшкә булган ихтыярын ныгыта. Аның бу гамәлләре чын геройлык, чын ватанпәрвәрлек үрнәге булып тора.

2 группа. Рүзәлнең ватанпәрвәрлеге һәм туган якка мәхәббәте хәрби зонага ярдәм итү белән генә чикләнми. Ул үзенең туган авылының да чын патриоты. Авыл кешеләренең тормышын яхшырту, туган җирнең тарихын саклау, киләчәк буыннарга үрнәк калдыру – бу да аның эшчәнлегенең мөһим юнәлеше. Ул туган авылына булган сөюен һәр адымында, һәр гамәлендә күрсәтә.

Күптән түгел Рүзәл махсус операциядәге егетләргә багышлап, туган авылы Метрәйдә «Егет без» дигән чишмә ачты. Чишмә – ул татар халкы өчен изге урын, шуңа бу изге эшкә авылдашлары һәм фикердәшләре бик теләп кушылды. Шушындый уртак эшләр авыл халкының бердәмлеген, дуслыгын ныгыта, аларның туган җирләренә булган мәхәббәтен арттыра.

Шул ук чишмә янында, Рүзәл Минһаҗев инициативасы белән, окоплар да ясадылар. Әйе, окоплар! Хәрби зонадагы чынбарлыкны, солдатларыбызның нинди шартларда илебезне саклавын халыкка ачык итеп күрсәтү максатыннан, ул шундый гадәти булмаган адымга барды. Бу эшне ул гади бер уен итеп түгел, ә чын күңелдән, тирән мәгънә салып оештырды. Аның максаты – халыкка сугыштагы егетләрнең батырлыгын, фидакарьлеген аңлату, аларның көрәшенә хөрмәт уяту.

Бу окопларны казуда олысы да, кечесе дә катнашты. Эш барышында Рүзәл егетләребезнең авыр хезмәте турында сөйләде, аларның батырлыкларын, чыдамлылыкларын аңлатты. Авыл халкы чынбарлык белән йөзгә-йөз очрашкандай булды. Алар окопларның нинди булуын, аларда яшәүнең ни дәрәҗәдә катлаулы икәнен аңладылар. Бу эш авыл халкында бик зур тәэсир калдырды, аларның күңелләрендә ватанпәрвәрлек хисләрен тагын да ныгытты, сугыштагы егетләребезгә карата ихтирамны арттырды. Бу – гади генә физик хезмәт түгел, бу – рухи тәрбия, патриотик дәрес, милләтнең бердәмлеген ныгытучы бер чара иде. Рүзәлнең бу инициативасы авыл тормышына яңа сулыш өрде, кешеләрне берләштерде һәм аларга мөһим тарихи вакыйгаларга карата үз мөнәсәбәтләрен белдерергә мөмкинлек бирде.

3 группа. Рүзәл Минһаҗевның тагын бер зур казанышы – ул аның ике китабының дөнья күрүе. Аның беренче китабы «Мин сокланам сиңа, кешелек» дип атала һәм 2021 елда бастырылды. Икенче китабы исә, махсус хәрби операциядә катнашкан егетләребезгә багышланган «Егет без!!!» дип исемләнгән һәм 2024 елда дөнья күрде. Бу китаплар – гади генә әсәрләр түгел, алар – хәрби зонадагы егетләребезнең җаны, рухы, аларның уй-фикерләре, сагышлары һәм өметләре тупланган рухи хәзинә. Китапның исеме үк – «Егет без!!!» – ниндидер бер эчке көч, горурлык, ныклык белән сугарылган. Ул безнең солдатларыбызның батыр рухын, аларның кыюлыгын, аларның Ватанга тугрылыгын чагылдыра. Бу сүзләрдә: «Без – чын егетләр, без – батырлар, без – үз Ватаныбызны саклаучылар!» дигән мәгънә ята.

«Егет без!!!» китабында оч йозгэ якын шигырь язылган. Һәрбер шигырь – солдат тормышының бер мизгеле, аларның кичерешләре, аларның дусларына, якыннарына булган мөрәҗәгатьләре. Бу шигырьләрдә Ватанга мәхәббәт, туган җиргә сагыш, фронт дуслыгының ныклыгы, дошманга каршы көрәшнең авырлыгы һәм гаделлеккә ышаныч чагыла. Рүзәл бу шигырьләрне язганда, ычшиксез, хәрби зонага булган сәфәрләрендә алган тәэсирләрен, егетләрнең сөйләгәннәрен, аларның күзләрендә күргәннәрен куллана. Һәр сүз аларның тавышы булып яңгырый. аларның йөрәге булып тибә.

Бу шигырьләрне укыганда, һәркем солдатның эчке дөньясына үтеп кергәндәй була. Анда сагыну да бар, моңсулык та бар, ләкин иң мөһиме – анда

ныклык, өмет һәм җиңүгә булган ышаныч ята. Бу шигырьләр егетләребезгә көч бирә, аларның рухын ныгыта. Алар бит беләләр: туган якта аларны сагынып, яратып көтәләр. Аларның батырлыклары бәяләнә.

«Егет без!!!» китабы хәрби хезмәткәрләр арасында зур популярлык казанды. Ул аларга авыр минутларда ял итәргә, үзләренең хисләрен аңларга, ялгызлыкларын онытырга булыша. Бу китапны укыган һәр солдат, үзенең бөтенләй ялгыз булмавын, туган якның аның белән бергә булуын аңлый.

Бу китап – тарихның бер өлеше, безнең заманның мөһим документларының берсе. Ул киләчәк буыннарга бу авыр вакытларны, безнең халкыбызның бердәмлеген һәм батырлыгын искә төшереп торачак. Рүзәлнең бу китаплары – аның иҗади сәләтенең дә, патриотик рухының да ачык чагылышы. Ул үзенең каләме белән дә Ватаныбызга хезмәт итә.

4 группа. Ләкин Рүзәл Минһаҗевның таланты шигърият белән генә чикләнми, аның күңелендә моң да, көй дә яши. Ул бик күп җырлар авторы да. Аның язган җырлары бүгенге татар эстрадасының иң якты йолдызлары башкаруында яңгырый, халыкның йөрәгенә үтеп керә. Бу җырларның һәрберсендә тирән мәгънә, эчкерсез хисләр ята, чөнки алар Ватанга, туган якка, мәхәббәткә, кешелеклелеккә багышланган. Аның иҗаты татар музыка дөньясына яңа сулыш өрде, аның җырлары халыкның күңеленә якын.

Мәсәлән, танылган җырчы Фирдүс Тямаев аның сүзләренә язган бик күп хитларны башкара. Алар арасында: «Егет без!» (солдатлар рухын күтәрүче гимн кебек), «Мәк чәчәге», «Калдырма мине», «Рәхмәт сиңа иркәм», «Тормыш арбасы», «Авыр бит», «Син», «Поезд чаба», «Авылыма», «Бик соң иркәм» һ.б. Бу җырлар Фирдүс Тямаевның репертуарының нигезен тәшкил итә, концерт залларын тутыра, тамашачының күңелен дулкынландыра.

Ведущий: Эти зловещие деяния гитлеровцев вызвали мощное сопротивление нашего народа. Вся страна превратилась в единый военный лагерь. В тылу врага разгорелась партизанская война. Чтобы не оказаться в фашистском рабстве, ради спасения Родины наш народ вступил в жестокий бой с врагами.

30 сентября 1941 года вермахт начал генеральное наступление на Москву. Фашистами было взято в плен много советских людей, захвачено 1242 танка и 5412 орудий. Но 5-6 декабря уже последовало мощное советское контрнаступление. Враг отошел от Москвы на 100-250 км, оставив города Калинин, Калугу, Клин, Волоколамск.

Ведущий: Особенно тяжело было пережить эту войну детям. Погибали дети не только на фронтах, но и в оккупированных фашистами городах и в блокадном Ленинграде. В течение 900 дней вся страна, весь мир, затаив дыхание, ловили любую весточку из Ленинграда, охваченного кольцом немецкой блокады. Начиная войну с СССР, Гитлер намеревался сровнять с землей и Москву, и Ленинград. Уничтожить город на Неве с помощью военной силы не удалось. Тогда Гитлер в январе 1942 г. цинично заявил: «Ленинград мы не штурмуем сознательно. Ленинград выжрет себя сам...»

Горожане все, от мала до велика, выстояли в эти тяжелейшие дни. Своим трудом, мужеством и стойкостью они приближали победу. И выстояли, и победили! Весь мир был потрясен героизмом ленинградцев.

В ознаменование подвига войск, массового героизма и мужества населения 26 января 1945 года указом Президиума Верховного Совета СССР Ленинград был награжден орденом Ленина, а 8 мая 1965 г. в честь 20-летия победы городу

было присвоено почетное звание «Город-герой» с вручением ордена Ленина и медали «Золотая звезда».

3-й чтец:

Какая музыка была!
Какая музыка играла,
Когда и души и тела
Война проклятая попрала.

Звучит песня «Священная война» (музыка А.Александрова, слова В.Лебедева-Кумача) в исполнении ансамбля им. А.В. Александрова

Ведущий: В истории есть критические точки или вехи, от которых целые народы ведут новый отсчет времени. Такой критической для судеб нашей страны и всей Европы стал Сталинград. Именно Сталинград предопределил конец гитлеровского рейха, разгром его военной машины…именно на развалинах Сталинграда, обагренных кровью его защитников, история вынесла фашизму свой окончательный приговор.

Двести дней и ночей на огромной территории в междуречье Волги и Дона не затихали ожесточенные бои. В сражении под Сталинградом с обоих сторон участвовало более двух миллионов ста тысяч солдат и офицеров, около 2500 боевых самолетов, почти 26 тысяч орудий, более двух тысяч танков и штурмовых орудий.

В результате были подорваны военная мощь и престиж Германии.

На всю страну прославились бойцы Красной Армии, два месяца удерживавшие оборону дома, который стал непреступной крепостью.

4-й чтец: Гулко катился в кровавой мгле
Сотой атаки вал.
Злой и упрямый, по грудь в земле
Насмерть солдат стоял.
Знал он, что нет дороги назад, -
Он защищал Сталинград.

Звучит музыка Л.Бетховена. Пятая симфония, часть 3

Ведущий: Давно закончилась война… Затекли и сравнялись с землей окопы, заросли травой временные фронтовые дороги, цветами покрылись блиндажи. Но земля всегда будет помнить о войне. И люди помнят! сквозь время говорят с нами те, кто уже никогда не вернется, не обнимет детей, внуков, друзей. Поклонимся же низко тем, кто положил свою жизнь на алтарь Отечества, почтим минутой молчания их память.

Минута молчания.

Ведущий: Склоняя головы перед светлой памятью отцов, дедов, братьев, сестер, родных, однополчан, друзей, освободим сердца от гнева и жестокости, вспомним, что мы – сыны и дочери великого народа, и будем достойны его.

Чтец: Вечная слава Героям!
Вечная Слава! Вечная Слава! ...
Но зачем она им, эта слава, — мертвым?
Для чего она им, эта слава, — павшим?

Все живое — спасшим. Себя — не спасшим. Для чего она им, эта слава, — мертвым?.. Если молнии в тучах заплещутся жарко

И огромное небо от грома оглохнет,

Если крикнут все люди земного шара, —

Ни один из погибших даже не вздрогнет. Знаю: солнце в пустые глазницы не брызнет! Знаю: песня тяжелых могил не откроет!

Но от имени сердца, от имени жизни Повторяю: Вечная Слава Героям!..

Литература:

1. Сборник стихотворений поэтов-фронтовиков.

2. Города-герои Великой Отечественной войны. – М.: Просвещение, 1975.

3. Данилов А. А. История России, XX – начало XXI: учеб. для 9 кл. общеобразоват. учреждений / А. А. Данилов, Л. Г. Косулина, М. Ю. Брандт – М.: Просвещение, 2008.

Без — Җәлил оныклары. Батырлык дәресе..

Башлангыч сыйныф укучылары өчен әдәби - музыкаль кичә

Нургалиева Алсу Ахметхановна,
Актаныш муниципаль районы
«Сәфәр урта гомуми белем бирү мәктәбе»
гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе

Максат: Балаларны Муса Җәлилнең тормыш юлы, иҗаты һәм сугышта күрсәткән батырлыклары, Җәлилчеләр белән таныштыру; М.Җәлил шәхесе һәм Җәлилчеләр белән горурлану, соклану хисләре тәрбияләү; Сөйләм телен үстерү, баету.

Бурычлары:

- укучыларда Муса Җәлил иҗатын өйрәнүгә кызыксыну тудыру;
- укучыларга патриотик тәрбия бирү;
- әдәби иҗатка сәләтле балаларны барлау һәм ачыклау;
- укучыларның сәләтләрен үстерергә ярдәм итү.

– өлкән буынга карата ихтирам, Туган илне ярату хисе тәрбияләү.

Зал бизәлеше: Кичә булачак зал бәйрәмчә бизәлгән. Төрле Муса Җәлилнең портреты һәм китаплары күргәзмәсе, Җәлилчеләргә багышланган презентация, балаларның рәсемнәре.

Талгын гына көй яңгырый.

1слайд күрсәтелә.

1. Хәтерләүдән курыкма син!

Батырларны онытма син!

2. Без — Җәлил оныклары

3. Әй, шагыйрьләр!

Яңгырасын үлемсез үлмәс җырыгыз!

4. Һәрвакыт булсын кояш!

Һәрвакыт булсын һава!

Һәрвакыт булсын әни!
Һәрвакыт булыйм мин!

Укытучы:
Кырык бишнең якты май таңында
Кояш булып Җиңү балкыган.
80 ел инде, җирне сөендереп,
Нурын сибә дөнья халкына.
Хәерле көн, кадерле балалар, кунаклар! Бүген без сезнең белән "Без — Җәлил оныклары" дип исемләнгән кичәгә җыелдык.

Магнитофон язмасында "Җиңү көне"җыры яңгырый.

1бала. Язлар саен көтеп алабыз
Без куанып Җиңү бәйрәме.
Сугыш юлын кичкән батырларга
Бирер өчен чәчәк бәйләм.
2 бала. Язлар белән туган якка
Килә Җиңү бәйрәме.
Онытмабыз батырларны
Без — Җәлил оныклары!

"Солдатлар" җыры башкарыла (Ф. Әхмәдиев муз., Р. Әхмәтҗанов сүз.)

Интерактив тактада Муса Җәлилнең әти – әнисе, үзенең шәкерт чагы,солдат киемендәге сурәте, һәйкәлләре һ.б. күрсәтелә.

3 бала. Муса Җәлил... Бу исем һәркемгә яхшы таныш. Шагыйрь, сугышчы, көрәшче. Бөек Ватан сугышы каһарманы.
4 бала. . Ул 1906 елның 15 февралендә Оренбург өлкәсендә туа. Кечкенәдән үк әдәбият белән кызыксына. "Бәхет" исемле беренче шигыре "Кызыл йолдыз" газетасында басыла. Мусага ул вакытта 13 яшь була.
5 бала. 1922 елда ул Казанга килә. Укырга керә. Аннары Мәскәүдә "Кечкенә иптәшләр" дигән балалар журналы редакциясендә җаваплы редактор булып эшли башлый. Бик күп шигырьләр яза.
6 бала. Гитлерчылар белән сугыш башлангач, Муса Җәлил фронтка китә.
7 бала. Илем! Алдында синең мин ант итәм
Шаһит булсын кулым ярасы.
Гитлер явын тар-мар итми торып
Якты күрмәс күзем карасы - дип яза ул.
8 бала. Әдип бер минут вакытын да әрәм итми, дошманга каршы корал белән дә ялкынлы шигырьләр белән дә көрәшә.
3 нче сыйныфлар "Ромашкалар" шигырен сәхнәләштерә.

Катнашалар: 1 нче ромашка, 2 нче ромашка, 3 нче ромашка, Кызыл ромашка, Солдат.(Салмак кына көй. Таң ата. Ромашкалар уяна).

1 ромашка: Хәерле иртә, туганнар!
Хәерле иртә, кояш!
Сезне яңа күрүемә
Мин, дусларым, бик тә шат!
2 ромашка: Хәерле иртә, табигать!
Хәерле иртә, кошлар!
Назлап исә таң җилләре
Чык сулары ап-ак саф.
(3 ромашка биюе).
3 ромашка: Чү, дусларым! Ни күрәм!
Бу ни бу, ой үләм?!
Әйт сеңелкәй, ни булды?
Кемнәр каннарын койды?
1 ромашка. Ап – ак синең таңларың,\
Ни өчен соң алланды?
Әллә берәр явызы
Берәрсен яралады?
2***ромашка***: Я, сеңелкәй, ач серең,
Сөйлә безгә син барын.
Ни өчен ак чукларың,
Синең бүген ал канлы?
3***ромашка***: Син, сеңелкәй ...
Ник үзгәрдең? Нишләдең?
Нидән кызыл чукларың,
Нидән алсу төсләрең?
Кызыл ромашка: Төнлә минем яныма
Ятып батыр сугышчы
Атты дошманнарына.
Ул берүзе сугышты
Унбиш укчыга каршы;
Чигенмәде, тик таңда
Яралады кулбашы.
(Кызыл ромашка сөләгән вакытта интерактив тактада сугыш сюжетлары күрсәтелә)
Кызыл ромашка: Аның батыр ал каны
Тамды минем чукларга.
Минем кызыл күлмәгем
Бик ошады Чулпанга.

Кызлар башкаруында "Катюша " биюе.

1 бала. 1942 елда ул әсирлеккә төшә. Җәлил һәм аның иптәшләре тоткынлыкта да дошманга каршы көрәшәләр. Гитлерчылар моны белеп алып, аларны җәзага тарта.

2 бала. Муса Җәлил белән бергә аның ун көрәштәше дә үлем җәзасына хөкем ителә. Аларның исменәрен хәтеребездә тотыйк!

Укучыларның кулларында Җәлилчеләрнең сурәтләре.

3бала: Үз иле, гаиләсе өчен
Батырларча ул сугышкан.
Оныклары рәхәт үссен диеп
Хәтта үзен кызганмаган.

4 ***бала***: "Сертотмас үрдәк"не язган
Сез аны беләсезме?
Төрле әкиятләрен укып,
Гыйбрәт аласызмы?

5бала. Муса абый ялгыз түгел, -
Иптәшләре бар ич:
Бер иптәше - әкиятче
Абдулла Алиш!

6Бала: Син — халкыңның батыр улы,
Исемең мәңге онытылмас:
Һәрчак безнең йөрәктә син —
Гайнан абый Кормаш!

7бала. Язмыш сынды төрле яклап
Кайчак була аяусыз —
Сынатмадың, халкым улы —
Әхмәт абый Симаев.

8бала б. Батырларны барлыйм, дисәң,
Тарих дәфтәрләрен актар:
Шундый батырларның берсе —
Абдулла абый Баттал!

9бала б. Җыр булып яши күңелдә
Хәсәнов Зиннәтулла!
Батырлар турында һәркөн
Шигырьләр, җырлар туа...

10 бала: Булгандыр ул да сабый
Кайчандир безнең кебек
Һәрчак безнең күңелдә син —
Шабаев Гариф абый!

11 бала: Ул батырларның берсе син-
Әхәт абый Әтнашев!
Дошманга каршы батырлар
Көрәшкәннәр берләшеп.

12 бала: Кыю иптәш һәм көрәштәш
Фоат абый Сәйфелмөлек.

Исемнәре мәңге балкый
Якты йолдызлар кебек.
13 бала: Тынычлык өчен көрәшкән
Фоат абый Булатов!
Урынығыз булсын оҗмахта,
Без Сезне онытмыйбыз.
14 бала: Ил-Ватанга ант итә
Газиз халкым уллары...
Антыңа тугры калды син-
Сәлим абый Бохаров!
1 бала. Безгә тыныч лык бүләк иткән Җәлилчеләрне, Муса Җәлилне онытмыйк!

Егетләр Муса Җәлил сүзләренә язылган "Акбай" җырын башкаралар.

15 бала: Җәлил абый шигырьләрен
Бик яратып укыйбыз.
Сугыштагы батырлыгын
Үрнәк итеп сөйлибез.
"Чәчәкләр " шигыренә композиция.
6 кыз (чәчәкләр) чыгып басалар.
- Барыгыз, болынга, балалар!
Йөгерегез, уйнагыз, көлегез!
Елмайсын күреп шат аналар, юансын боеккан күңлегез.
Болында күп матур чәчәкләр,
Барысы да татлы, хуш ислеләр
Нәркисләр, сөмбелләр һәм мәкләр
Нәкъ сезнең иренегез төслеләр.

"Чәчәкләр " биюе.
Укучылар Муса Җәлилнең "Мин әтигә ошаган", "Чулпанга", "Карак песи" шигырьләрен сөйлиләр.
16 бала: Муса абый сине һәрчак,
Хәтерләрдә саклырбыз.
Курку белмәс, шигъри җанлы
Син шагыйрь абыебыз!
Син батыр абыебыз!
Бергә: Хәтерләүдән курыкма син!
Батырларны онытма син!
Укытучы: Балалар, шушындый матур, тыныч тормышта яшәвебез белән без Муса Җәлил кебек шагыйрьләргә, Җәлилчеләргә, кадерле ветераннарыбызга бурычлы. Безнең теләк бер: илләр, көннәр тыныч, күгебез аяз, һәркем бәхетле, шат, сәламәт булсын! Сугышлар булмасын!

Җыр “Һәрвакыт булсын Кояш”.

"Тормышта батырлыкка һәрчак урын бар!" (В жизни всегда есть место подвигу"). Батырлык дәресе.

Целевая аудитория: школьники

Нуриахметова Римма Закиряновна,
МБОУ «Лицей №38»

Сыйныф сәгате «Батырлык дәресе»

Дәрестә кулланылган метод һәм алымнар: сүзлек белән эш, презентация күрсәтү, әңгәмә, сорауларга җаваплар бирү, карточкалар белән эшләү.

Максатлар һәм бурычлар

1. «Батырлык» төшенчәсен ачарга, батырлык мисалларыннан үрнәк китерергә.
2. Сугышның кырыс чынбарлыгын, Бөек Ватан сугышы елларында халыкның каһарманлыгын күрсәтергә, патриотлык һәм милли горурлык тәрбияләргә.
3. Ветераннарга хөрмәт һәм рәхмәт, кешелеклелек, җаваплылык хисе тәрбияләргә.
4. Сөйләм культурасын камилләштерергә, тыныч, сәламәт тормыш кыйммәтләренә игътибарны җәлеп итәргә.

Эпиграф

«Батырлык ул — рухи матурлык… Әнә шуңа күрә дә халкыбыз кеше күңеленең рухи бөеклеген югары бәяләгән. Батырларның кылган изге гамәлләре, данлы исемнәре әкиятләргә күчкән, җырларга кергән».

Минтимер Шәймиев

Дәрес барышы

I. Оештыру моменты.

- «Исәнмесез, хәерле көн, укучылар!»
- "Батырлык" сүзен сез ничек аңлыйсыз?",
- "Кемне батыр кеше дип атарга мөмкин?»

- Батырлык - ул курку белмәү түгел, ә аңа каршы эш итә белү.

Бу сугыштагы батырлык кына түгел, гади тормыштагы рух көче дә.

II. Укытучының кереш сүзе

1. Р. Миңнуллинның «Батыр булыгыз»дигән шигырен укып китәм.

Батырлыкны эшли ала
Бөтен кеше дә.
Аның өчен кирәк түгел

Алып көче дә.
Ә моның өчен:
Яратырга кирәк бары
Туган җиреңне,
Әти-әниеңне,
Туган илеңне.

2. Сораулар аша әңгәмәгә кушылу.

- Кешеләр нәрсәдән курка? (Чего боятся люди?)
- Кешеләр нәрсә тели? (Чего хотят люди?)
- Батыр кем ул? (Кто такой батыр?)
- Батырлык кайдан башлана? (С чего начинается мужество?)

3. Төрле ситуацияләрдә сыйфатларның чагыштыру мисаллары, тыңлагыз әле.

1. Янгын: кеше - кешеләрне коткару өчен янган бинага ташлана. (батырлык + фидакарьлек).

2. Һөҗүм: үзе өчен куркыныч булуга карамастан көчсезне яклап баса. (катгыйлык + кызгану).

3. Гадәттән тыш хәл: эвакуация оештыра, паникага бирелүчеләрне тынычландыра. (җаваплылык + оптимизм).

Нәтиҗә: Чын герой - физик яктан көчле кеше генә түгел, ә югары әхлаклы шәхес тә булырга тиеш. Аның гамәлләре данга омтылу белән түгел, ә башкалар турында кайгырту гамәле дә. Геройлык төрле ситуацияләрдә дә, көндәлек игелекле эшләрдә дә чагыла.

4. Мәкальләр белән эшләү (карточкаларда яки тактада):

Укучылар мәкальләрнең мәгънәсен аңлаталар һәм тормыштагы мисаллар белән чагыштыралар.

1. Батыр яуда беленер.
2. Батыр үз халкын яклый.
3. Батырлыкта — матурлык.

5. Геройның төп сыйфатлары:

а). Кыюлык

- Башкалар өчен куркыныч булуга карамастан каршы барырга әзерлек.

-Кешеләрне коткару өчен сәламәтлекне һәм тормышны куркыныч астына кую сәләте.

- Риясызлык — бүләк яки танылу турында уйламау.

б). Рух көче һәм ныклык.

- Изге максатка ирешүдә үҗәтлек.
- Авырлыкларны, авыртуны кичерү сәләте.

- Сынаулар алдында бирешмәү.

в). Җаваплылык һәм бурыч хисе
- Үз гамәлеңнең башка кешеләр өчен мөһимлеген аңлау.
- Үз өстенә алган йөкләмәләрне, хәтта катлаулы шартларда да үтәү.
- Үз гамәлләреңнең нәтиҗәләрен аңлау.

г). Кызгану һәм кешелеклелек
- Башкаларның кайгысын уртаклаша белү.
- Көчсез, яклаусыз кешегә ярдәм итү теләге.
- Кешеләргә, хәтта дошманнарга да кешелекле мөнәсәбәт.

д). Тәвәккәллек

- Кискен вәзгыятьтә карарларны тиз кабул итү сәләте.

- Инициатива-күрсәтмәләр көтү түгел, ә беренче булып эш итү.

ж). Намуслылык
- Үз ышануларыңа һәм әхлакый нормаларга тугрылык.
- Хәтта басым астында да бирешмәү.
- Герой дан өчен эшләми.

з). Басынкылык
- Батырлыкны «батырлык " буларак түгел, ә табигый гамәл буларак кабул итү.
- Үз казанышларыңны арттырмау.

и). Кайгыру
- Башка кешеләрнең хисләрен аңлау.
- Үзеңне ярдәмгә мохтаҗ кеше урынына кую сәләте.

к). Өмет
- Хәтта иң авыр шартларда да ышанычны югалтмаска.
- Тирә-юньдәгеләргә ышаныч уята белү.
- Башка кешеләрнең әхлакый рухына ярдәм итү.

2. Физкультминут

Балалар музыкага бииләр. Музыка туктагач, алар парлап торырга һәм бер-берсен ишарә белән сәламләргә тиешләр.

III. Уку мәсьәләсен адымлап чишү

1.Төркемнәрдә тикшерү өчен сораулар

- Ә менә сез батырлыкны ничек аңлыйсыз ?
- Нәрсә соң ул батырлык?

Моның өчен безгә группаларга берләшергә кирәк. Мин сезгә батыр кеше нинди булырга мөмкин, шул сыйфатлар язылган карточкалар өләшәм, ә сез шуларны икегә аерырсыз: кайсылары батырлык дуслары, ә кайсылары батырлык дошманнары икәнен билгеләрсез.

- Ягез әле, батырлык дуслары нинди сыйфатлар икән?
- 1 группа
- 2 группа
- 3 группа

Бу сыйфатлар беркайчан да батырлык белән янәшә йөри алмыйлар. Алар булган җирдә батырлык яши алмый.

Рәхмәт урыннарыгызга утырыгыз.

Нәтиҗә:

Димәк, батыр кеше нинди сыйфатларга ия икән?

Укучыларның җаваплары тыңлана:

- Әйе, бу сыйфатлар кешеләргә элек-электән үк хас. Кешеләр дошманнарына каршы батырларча көрәш алып барганнар.

Батырлык дәресендә кыюлык, фидакарьлек һәм экстремаль ситуацияләрдә ярдәмгә килергә әзерлекне күрсәтүче заманча батырлык мисаллары турында фикер алышырга мөмкин. Бу вакыйгалар батырлыкның сугыш кырында гына түгел, ә кеше башкаларны коткару өчен тиз һәм катгый хәрәкәт иткән көндәлек тормышта да чагылуын күрсәтә.

2.Экстремаль ситуацияләрдә батырлык үрнәкләре:

1. Ислам Хәлилов-2024 елда «Крокус Сити Холл " дагы теракт вакытында 100дән артык кешене эвакуацияләгән, 15 яшьлек мәктәп укучысы. Ул концерт залы гардеробында эшләгән һәм атыш башлангач, кешеләргә чыгарга булышкан. Аларны хезмәт бинасы аша урамга чыгарган.

2. Олимжон Ибраһимов - янгын вакытында өченче катка менгән һәм янган фатирдан яшәүчеләрне тартып чыгарган дворник.

3. Рза Рзаев - 2024 елның гыйнварында Новосибирскида коммуналь авария аркасында кайнар су белән тулган урам аша, кешеләрне кулларында йөрткән грузчик. Балаларны коткару өчен ул берничә тапкыр кайнар су буйлап барган.

4. Альберт Бикмуллин - 2024 елның февралендә Казанда ике яшьлек игезәкне коткарган машина йөртүче. Ул йөк машинасында күпфатирлы йорт яныннан узып барганда елау һәм кычкырулар ишетә. Бишенче каттагы ачык тәрәзәдә ир-ат ике кечкенә баласын тоткан һәм аларны ташлау белән янаган. Машина йөртүче, подъезд козырегына менеп, әтисен акылга утыртырга

тырышып караган. Ир-ат баланы тәрәзәдән ыргыткач, Альберт кызны тотып ала һәм аның белән көрткә тәгәрәп төшә. Шуннан соң ул баланы үтеп баручыларга тапшырган, ә үзе фатирга, күрше фатир тәрәзәсе аша эләккән һәм икенче баланы алган.

5. Захар Аникин - 2024 елның мартында, баткан икенче сыйныф укучысын коткарган. Сочидан, 14 яшьлек яшүсмер. Ул, бер дә уйламыйча, суга ташланган. Захар малайны ярга алып чыккан һәм әнисенә шалтыраткан.

6. Богдан Миряшин - Донецк Халык Республикасыннан, 16 яшьлек кадет. Ул 2024 елда ВСУ һөҗүме вакытында пенсионерларга, күпкатлы йорттагы янгыннан котылырга ярдәм иткән.

7. Әмир Абачев - Мәскәү өлкәсеннән, 9 нчы каттан егылып төшкән дүрт яшьлек баланы тоткан, мәктәп укучысы. Әмир дуслары белән йөргәндә, тәрәзә рамы кырыенда йөргән сабыйны күргән. Ул дусларына ян-якка басарга кушкан, ә үзе уртага баскан. Шулай итеп, баланы коткарып калган.

8. Сергей Кастырин - көчле агымга эләккән ике укучыны коткарган, Воронеж егете. Кайчандыр ул йөзү белән шөгыльләнгән, шуңа күрә батып баручы абыйлары янына йөзеп барып, аларны ярга чыгара алган.

3. Шулай ук хәрби хәрәкәтләр барышында батырлык күрсәткән заманча хәрбиләрне дә искә алырга мөмкин.

1.Эммануил Давыдов (позывной «пономарь») — ике атна буе Курск өлкәсендә, Украина боевикларының һөҗүмен тоткарлаган яшь командир. Чолганышта элемтәсез калгач, ул берүзе ударларны кире кайтара. Соңрак Давыдов дошманның радиостанцияле техникасын кулга төшерә, дошманның хәрәкәт маршрутында засада оештыра.

2.Павел Евлашевич — ДНРның иң кайнар юнәлешләрендә сугышкан командир, Селидово өчен сугышларда аерылып торган һәм бер тапкыр да чигенмәгән. Аның бүлекчәсе штурмовиклары ДНРда берничә торак пунктны азат иткән.

Нәтиҗә:

Бу мисаллар күрсәткәнчә, батырлык - ул физик батырлык кына түгел,ә үз тормышың өчен куркыныч булуга карамастан, тиз арада карарлар кабул итү, фидакарьлек белән эш итү һәм башкаларга ярдәм итү сәләте дә.

IV. Йомгаклау

1. Рефлексия:

- "Бүген үзегез өчен батырлык турында нинди ачыш ясадыгыз?
- Минем яшьтә батыр булу - димәк...
- Батыр булу өчен нинди сыйфатлар кирәк?
- Тыныч тормышта ничек батырлык күрсәтеп була?

Укытучы җавапларны гомумиләштерә. “Батырлык — көч кенә түгел, игелеклелек, ярдәм итәргә әзерлек, Ватанга мәхәббәт ул”.

Нәтиҗә:

Җир йөзендә сугышлар кабатланмасын,

Яшь егетләрнең гомерләре вакытсыз өзелмәсен,
Әти-әниләр кайгы яше түкмәсен иде.

2. Өй эше (сайлап алына):

1. «Сугышсыз дөнья» темасына рәсем ясарга;
2. Бабайның сугыш яки тыныч вакыттагы батырлык турындагы хикәя язып килергә;
3. Батырлык турында шигырь ятларга.

Нәтиҗә:

Батырлык дәресе, укучыларның күңелендә батырлык турында белем бирү генә түгел, ә эчке ориентир — батырлыкның мәхәббәттән, җаваплылыктан һәм хәтта авыр булганда да, дөрес юл сайлау, аңлау булырга тиеш.

Мастер- класс для педагогов.
«Родину любят душой».

Целевая аудитория: учителя

Садыкова Лилия Талгатовна,
МАОУ «СОШ№3» города Нурлат

Цель: повысить компетентность педагогов в вопросах нравственно-патриотического воспитания посредством использования патриотической песни.

Задачи :

Представить педагогическому сообществу опыт работы по нравственно-патриотическому воспитанию средствами песен.

Участники: педагоги

Ход мастер-класса:

Уважаемые коллеги, воспитывая ребенка, мы с вами надеемся вырастить из него достойного человека, патриота своей Родины.

Педагог: Здравствуйте уважаемые коллеги, я рада Вас всех приветствовать ! Вашему вниманию представляю мастер- класс на тему: «Родину любят душой»

Патриотизм нельзя потрогать! Он не предметный! Его можно почувствовать. Наш сегодняшний мастер- класс будет посвящен нашей душе умению чувствовать себя частью великой страны, ощутить свою привязанность к Родине.И каким бы затертым и каким бы набившим осколину не были слова патриотизм мы с вами каждый чувствуем себя - частью своего народа и своей нации !

Предлагаю поговорить по душам!

Педагог: Когда разговаривает душа? (душа разговаривает когда поем)

А поем мы и в горе и в радости!

Вместе с вами мы начнем наш Мастер- класс с игры «Угадай мелодия»

В наше время все чаще люди забывают о песнях которые посвящены той теперь уже далекой войне.

Для вас прозвучат мелодии военных песен .

Вам нужно будет прослушать и отгадать название песен !

(10 песен)

1. Синий платочек

2.Три танкиста

3.Темная ночь

4.Огонек

5.Эх дороги

6.Казаки в Берлине

7.На безымянной высоте

8.В землянке

9.Священная война

10.Катюша

Педагог :Какая из этих песен стала известной всему миру ?

(Катюша)

-Хорошо ли мы ее знаем ?

Предлагаю поработать именно с этой песней .

Участники которые угадали песни сели за отдельный стол.(на столе лежат картинки подходящие на куплеты песни «Катюша»)

Предлагаю вам вспоминая текст песни «Катюша» собрать кадры из картин Один кадр –один куплет .

А в это время остальные участники отвечают на вопросы:

1.Кто из вас может назвать авторов песни «Катюша»?

2 .А как вы думаете когда была написана «Катюша»?

3. Вспомните пожалуйста кто первым исполнил «Катюшу»?

4. Кто может из вас назвать сколько версий слов Катюши известно

Ответами на вопросы будет служить строка из песен :

Какие деревья расцветают в стихотворении?

Яблони и груши

6.Куда выходила Катюша?

На берег

7.Какими эпитетами автор описывает берег?

Высокий, крутой

8.Что делала на берегу Катюша?

Заводила песню

9. О какой птице пела Катюша?

О степном орле

10. Про какого человека Катюша пела песню?

«Про того, которого любила,/ Про того, чьи письма берегла»

11.За чем вслед автор просит лететь песенку Катюши?

За ясным солнцем

12. Кому автор просит передать привет от Катюши?

Бойцу на дальнем пограничье

13. Что по мнению автора должен беречь любимый Катюши?

Родину

14. Что должна сберечь Катюша по мнению автора?

Любовь

Спасибо !

Теперь участники ,которые собирали кадры к песни пожалуйста смонтируйте фильм по куплетам !

А теперь давайте проверим правильность выполнения работы!

Пропойте каждому кадру куплет из песни показывая на картинку.Спасибо!.

Внимание на экран! (на экране слова песни «Катюша»)Теперь самое интересное !

Попробуем рассмотреть невидимое в этой песне.

Вопросы к тексту

1. На какой территории нашей страны происходит это событие данной песни

Где яблони цветут и груши одновременно ?

Какое время суток пришла Катюша на берег ?

Какое время года ?

На берегу какой реки могла стоять Катюша ?

У какой реки самые крутые берега ?

Где служил ее боец ?

Род войск юноши (пограничник)

Сколько лет бойцу? (18 лет)

Как долго Катюша стояла? (3 года)

-Спасибо !

Вывод:

На примере одной песни мы сегодня с вами окунулись в географию страны ,учились читать между строк. Почувствовали силу любви и верности .

Учились патриотизму ведь наш воин охранял границу Родины !

Сегодняшний день не проще другого дня в истории нашей страны.

Нашим спортсменам запрещают использовать гимн выходить под родным флагом. Но русский умен хитрым умом! Этот ролик доказательство тому !

С первых звуков этой песни всем стало понятно представители какой страны выступают !(**Внимание на экран)Ролик про спортсменов ,которые выходили под песню «Катюша»**

Где бы не были в какую страну бы мы не приехали на каком бы языке нашей необъятной родины мы не говорили мы всегда остаемся русскими!

Родина у нас в душе ! Пусть наша душа поет всегда !

Эта песня стала символом Родины, символом любви и верности.

И пока память жива эта песня будет звучать в нашей жизни ,в названии военного оружия в памятниках и в музеях нашей истории.А закончить я хочу свой мастер класс с песней которую мы вместе пропоем . «Катюша»

(Такой мастер –класс можно провести на примере и других песен)

Урок мужества.
“Я люблю свою Родину и всегда готов ее защищать”.

Самигуллина Флюра Хакимовна,
Муниципальное бюджетное
общеобразовательное учреждение
«Чулпановская средняя общеобразовательная школа
Нурлатского муниципального района Республики Татарстан»

Дәрес эшкәртмәсе
Тема: “Мин туган илемне яратам, аны сакларга һәрвакыт әзер!”
(урта сыйныфлар өчен)

Максат:

- Укучыларда Ватанга карата мәхәббәт, горурлык хисләрен тәрбияләү, патриотик рухны үстерү.
- Туган илне саклауның мөһимлеген аңлату, гражданлык җаваплылыгын формалаштыру.
- Укучыларның фикерләү сәләтен, аралашу күнекмәләрен, иҗади активлыгын үстерү.

Бурычлар:

- Ватан, туган ил, патриотизм төшенчәләрен ачыклау, аларның әһәмиятен билгеләү.
- Татарстанның тарихы, мәдәнияте, табигате белән таныштыру, аның үзенчәлекләрен күрсәтү.
- Туган илне саклаучы батырлар, геройлар турында сөйләү, аларның батырлыгына хөрмәт тәрбияләү.
- Хәзерге заманда Ватанны ничек сакларга мөмкин икәнлеге турында фикер алышу, укучыларның үз фикерләрен белдерү мөмкинлеген тудыру.
- Дәрес дәвамында төрле интерактив алымнар куллану, укучыларның активлыгын арттыру.

Дәрескә кирәкле материаллар:

“Ватан”, “туган ил”, “патриотизм” төшенчәләре язылган карточкалар, Бөек Ватан сугышы турында презентация, өчпочмаклы хатлар, “Шифрлау” уены өчен шифрланган саннар, Алфавит, солдат белән медсестра костюмнары; “Минем фикерем” дигән интерактив уен өчен сораулар, плакат ясау өчен ватман битләре; Бөек Ватан сугышы геройлары турында презентация (М. Җәлил, М. Девятаев, П. Гаврилов һ.б.), Интерактив такта, компьютер, интернет, Татарстан турында презентация (фотосурәтләр, видеоматериаллар, музыка), Патриотик җырлар язмалары, карточкалар (цитаталар, сораулар, биремнәр), кәгазьдә эшләү өчен материаллар (каләм, карандаш, маркерлар, кәгазь).

Дәрес барышы:

I. Оештыру моменты.

- Укытучының укучылар белән исәнләшүе.
-Укучыларның дәрескә әзерлеген тикшерү.

-Уңай психологик халәт тудыру (мәсәлән, бер-берсенә яхшы теләкләр әйтү).

II. Мотивация

Укытучы: Хөрмәтле укучылар! Бүген без сезнең белән бик мөһим һәм җитди темага сөйләшербез. Бу тема һәрберебезнең йөрәгенә якын, чөнки ул безнең Ватаныбызга, туган илебезгә багышлана. Әйтегез әле, сезнең өчен Ватан дигән сүз нәрсә аңлата?

Укучыларның җаваплары тыңлау, фикер алышу:

-Ватан – минем туган ягым. Бу минем туып-үскән җирем, мин шунда беренче адымнарымны ясадым, беренче сүзләремне әйттем;

-Ватан – минем гаиләм, минем туганнарым. Алар мине яраталар һәм минем өчен кайгырып торалар;

Ватан – минем телем, мәдәниятем, гореф-гадәтләрем, тарихым.

Укытучы: Әйе, дөрес әйтәсез, Ватан – ул безнең туган җиребез, безнең тарихыбыз, мәдәниятебез, безнең халкыбыз. Безнең Ватаныбыз – Татарстан! Без аны яратабыз, аны сакларга һәрвакыт әзер булырга тиешбез!

Дәреснең темасын һәм максатын игълан итү.

III. Актуальләштерү

Укытучы: Ә хәзер, әйдәгез, бергәләп искә төшерик әле, “Ватан”, “туган ил”, “патриотизм” төшенчәләре нәрсә аңлата?

Укучыларга карточкалар тарату (һәр карточкада бер төшенчә язылган).

Укучыларның бу төшенчәләргә аңлатма бирүләрен сорау.

Укытучы төшенчәләрне ачыклый, кирәк булса, өстәмә мәгълүмат бирә.

Ватан – кешенең туган ягы, аның тарихы, мәдәнияте, халкы белән бәйле булган территория.

Туган ил – кешенең туып-үскән, яшәгән җире.

Патриотизм – Ватанга карата мәхәббәт, аңа тугрылык, аны сакларга һәм үстерергә әзерлек.

Укытучы: Патриотизм һәр кеше өчен дә мөһим сыйфатмы? Сез ничек уйлыйсыз?

Укучыларның фикер алышуын оештыру.

Җавап вариантлары:

-патриотизм бер төрле генә була алмый. Һәр кеше Ватанына мәхәббәтен үзенчә белдерә ала: берәүләр фронтта көрәшә, икенчеләр фәнни ачышлар ясый, өченчеләр балалар тәрбияли;

-патриотизм кешене үз Ватанына, халкына бәйли. Патриот кеше үз иленең тарихын, мәдәниятен хөрмәт итә, аны сакларга һәм үстерергә тырыша;

- патриотизм ул кешене җаваплы итә. Патриот кеше үз иленең киләчәге өчен борчыла, аның яхшыруына үз өлешен кертергә тырыша.

IV. Яңа материалны өйрәнү

Укытучы: Безнең Ватаныбыз – Рәсәй, Татарстан – бик бай һәм матур төбәк. Ватан тарихы, мәдәнияте, табигате уникаль һәм кабатланмас. Менә шушы рухи һәм матди байлыкны 81 ел элек бабайларыбыз фашизм белән сугышта яулап алган, саклап калган һәм безгә тыныч тормыш та бүләк иткән. Әйдәгез, хәзер Бөек Ватан сугышы елларына әйләнеп кайтыйк.

Интерактив тактада Бөек Ватан сугышы турында презентация күрсәтәбез (фронттагы батырлыкны, тылдагы батырлыкны, заводларда, фабрикаларда эшләүчеләрнең, колхозчыларның фидакарь хезмәтен, фронтка ярдәм итүне, балалар һәм яшьүсмерләрнең батырлыгын, аларның фронтка ярдәм итүләрен, партизан отрядларында катнашуларын, тылда эшләүләрен күрсәтү).

Презентацияне карау вакытында укытучы кыскача аңлатмалар бирә, кызыклы фактлар сөйли, укучыларның сорауларына җавап бирә.

Укытучы: Балалар, сугыш елларында Татарстаныбызның өлешен ничек күзалдына китерәсез? аның нинди үзенчәлекләрен аерып күрсәтер идегез? Бу урында дәреслек материалларын, шулай ук интернет челтәрен файдаланырга мөмкин. Укучылар җавапларны мөстәкыйль эзләп табалар.

Укучыларның җавапларын тыңлау, фикер алышу:

Татарстанның Бөек Ватан сугышына керткән өлеше турында укучылар түбәндәге материалны эзләп табалар:

-Фронтка киткән татарстанлылар саны: 700 меңнән артык кеше;

-Һәлак булган татарстанлылар саны: 200 меңнән артык кеше;

-Советлар Союзы Герое исемен алган татарстанлылар: 200 дән артык кеше;

-Тылда эшләүчеләрнең хезмәте дә көчле була - тылдагылар заводларда хәрби техника җитештерү, авыл хуҗалыгы продукциясе белән тәэмин итү белән шөгыльләнә;

-Мәдәният һәм сәнгать әһелләренең фронтка ярдәме дә көчле була – алар концертлар, спектакльләр, патриотик әсәрләр иҗат итәләр.

Укытучы: Балалар, сезгә алдан әзерләнеп килергә кушылган иде. Әби-бабайларыгыз сөйләвеннән сез сугыш еллары турында ниләр белеп калдыгыз. Бу белемнәрне сез өчпочмаклы хатка язырга тиеш идегез. Әйдәгез шул хатлар белән танышыйк.

Берничә бала класс алдында әби-бабасы сөйләгәннәрне исенә төшереп язган вакыйгаларны өчпочмаклы хаттан укып сөйли.

Укытучы: Балалар, бик яхшы әзерләнгәнсез. Безнең әби-бабайларның тормышы ул елларда бик авыр булган. Без шуны онытмасак иде. Бүгенге тыныч тормышның бәһәсе бик кыйммәт икәнен без барыбыз да аңларга тиеш. Күпме якын кешеләребез яу кырыннан кайтмады, күбесе хәбәрсез югалды.

Укучылар, без сезнең белән хәзер берничә уен уйнап китәрбез. Бу уеннарда Бөек Ватан сугышына, Бөек җиңүгә кагылышлы сораулар калкытылыр.

№1. “Шифрлау” уены (уенда балаларның логик фикерләве, игътибары, тарих буенча белемнәре үстерелә). Укучыларга Бөек Ватан сугышына бәйле шифрланган хәбәр бирелә. Укучылар шифрны чишәргә тиеш. Шифр төрле булырга мөмкин (мәсәлән, хәрефләрне саннар белән алыштыру, сүзләрне киресенчә язу һ.б.).

- / ЗЕБИМӘЛЕТ ШЫГУС ЗЕБ /БЕЗ СУГЫШ ТЕЛӘМИБЕЗ!

Аа	Әә	Бб	Вв	Гг	Дд	Ее	Ёё
Жж	Җҗ	Зз	Ии	Йй	Кк	Лл	Мм
Нн	Ңң	Оо	Өө	Пп	Рр	Сс	Тт
Уу	Үү	Фф	Хх	Һһ	Цц	Чч	Шш
Щщ	Ъъ	Ыы	Ьь	Ээ	Юю	Яя	

Алфавиттан бирелгән саннар буенча хәрефләрне җыярга.

/ 20, 2, 28, 16, 2, 22, / 3, 13, 1, 13, 15, 1, 20, 35, 2, 35, 11, 1 / РӘХМӘТ БАБАЙЛАРЫБЫЗГА!

№2. “Рольле уен”. Әлеге уенда укучыларның коммуникатив күнекмәләре ныгый, тарихи вакыйгаларны аңлау тирәнәя, эмпатия үсә.

Класс ике командага бүленә. Укучыларга Бөек Ватан сугышы чорындагы төрле рольләр бирелә (солдат, медсестра, тыл эшчесе, бала һ.б.). Укучылар бу рольләрдә диалоглар уйнарга тиеш.

Беренче командадан ике укучы солдат белән медсестраның әңгәмәсен уйнап күрсәтә:

Күренеш: Сугыш кыры. Шартлаулар тавышлары ишетелә. Яралы солдат авырлык белән ыңгыраша. Янына тиз-тиз генә медсестра килә.

-Зәйнәп: (борчылып) Егет, егет! Син исәнме? Кайда яраландың?

-Айрат: (авыр тын алып) Аягым... Аягым бик нык авырта...

-Зәйнәп: (аягын карый, канны туктатырга тырыша) Бик тирән яра түгел кебек. Хәзер бәйләп куярмын. Сабыр ит, егет. Исемең ничек синең?

-Айрат: Айрат... Минем ярам бик авырта... Һәм салкын...

-Зәйнәп: (өстенә плащын яба) Салкын тимәсен. Бераз түз. Хәзер укол ясармын, авырту басылыр. Каян син үзең, Айрат? Гаиләң бармы?

-Айрат: (күзләрен йома) Мин... Мин Казаннан... Өйдә әнием көтә... Бик борчыла торгандыр инде...

-Зәйнәп: Әниең горурланырлык улы булганына сөенергә тиеш! Син батыр егет, Айрат! Менә күрерсең, тиздән терелерсең дә, әниең янына кайтырсың... һ.б.

Икенче команда диалогның ахырын уйлап бетерә:

-Айрат: Ышанасы килә... Ләкин... Ләкин аягым... ләкин башка солдатларга да ярдәм итәргә агышырга кирәк....

-Зәйнәп: Бу синең турында кайгыртмыйм дигән сүз түгел. Мин хәзер сиңа беренче ярдәмне күрсәтәм, аннары башкаларны да караячакмын. Без беркемне дә ташламыйбыз. Безнең эшебез – кешеләрне коткару. Һәрберсенең гомере кадерле.

-Айрат: Сез... Сез бик кыю кыз... Мин сезгә рәхмәтлемен...

-Зәйнәп: Рәхмәт кирәкми. Бу минем эшем. Син хәзер ял ит. Укол эшләдем, авырту басылыр. Тиздән санитарлар килер, сине госпитальгә алып китәрләр.

-Айрат: Рәхмәт... Сезгә... Һәм... Җиңү белән кайтыгыз...

-Зәйнәп: Җиңү безнең белән булачак, Айрат. Моңа ышан! Безнең халкыбыз җиңелмәс! Хәзер йокла.

-Зәйнәп (башка яралылар янына китә)

-Күренеш тәмам.

Укытучы: Бик яхшы, балалар! Ә хәзер тыл күренеше буенча диалогларны тыңлап китик.

Беренче команда чыгышы:

Күренеш: Татар авылы. 1942 елның кышкы киче. Кечкенә өй эче. Өстәл янында ике хатын – Мәрьям әби (60 яшь) һәм Гөлчәчәк (25 яшь). Гөлчәчәк солдатларга җибәрү өчен җылы оекбаш бәйли, Мәрьям әби шәм яктысында хат укый.

-Мәрьям әби: (күз яшьләрен сөртеп) Улымнан хат килгән... Исән-сау әле, ди... Сугыш кырларында бик авыр, ди...

-Гөлчәчәк: (оекбашын бәйләүдән туктап) Әйттеме соң, кайда сугыша?

-Мәрьям әби: Сталинград янында, ди... Анда хәзер урам сугышлары бара, ди... Көн саен диярлек үлем белән күзгә-күз очрашабыз, ди...

-Гөлчәчәк: Безгә дә көн саен фронтка ярдәм җибәрергә кушалар. Кемдер бәйли, кемдер тегә, кемдер азык-төлек җыя... Барысы да – җиңү өчен!

Мәрьям әби: Әйе, кызым... Безнең тылда да җиңел түгел. Ирләр фронтта, ә безгә, хатын-кызларга, балаларга, бөтен авырлык төште. Җирне дә сөрәргә, игенне дә урырга, малны да кararга кирәк...

-Гөлчәчәк: Мин дә көн саен колхозда эшлим. Иртәдән кичкә кадәр... Арка да, куллар да авырта... Ләкин зарланмыйм. Без җиңәргә тиеш! Безнең җирне фашистлардан сакларга кирәк!

-Мәрьям әби: Дөрес әйтәсең, Гөлчәчәк... Зарланырга вакыт юк. Безгә көчле булырга кирәк. Без – тыл, без – фронтның терәге. Ирләребезгә ышаныч бирергә тиешбез.

Диалогны икенче команда дәвам итә:

-Гөлчәчәк: Син хаклы, әби... Әйдә, мин сиңа чәй ясап килим. Бераз җылынырсың.

-Мәрьям әби: Рәхмәт, кызым. Ләкин син утыр әле, бәйләвеңне дәвам ит. Солдатларга җылы оекбаш бик кирәк хәзер. Ә мин хатны кабат укып чыгыйм. Улымның һәрбер сүзен йөрәгем аша уздырам...

-Гөлчәчәк: Әби, мин бер җыр беләм... Әйдә, бергәләп җырлыйк! Күңел күтәрелер... Җыр – безнең көчебез!

Мәрьям әби: (елмая) Әйдә, кызым... Ничек дигән җыр иде әле ул?

Гөлчәчәк: (җырлый башлый)

Мәрьям әби: (җырны дәвам итә)

(Икесе бергә җырлыйлар)

Гөлчәчәк: Җырлагач, күңелгә ничектер җиңелрәк булып китте, әби.

Мәрьям әби: Әйе, кызым... Җыр – ул безнең өметебез, безнең көчебез. Без бергә булсак, без бернәрсәдән дә курыкмабыз! Җиңү безнең белән булачак!

Укытучы: бик күркәм, балалар!

V. Ныгыту

Укытучы: Туган илебезне ярату җитми, аны сакларга да кирәк. Ә сез ничек уйлыйсыз, Ватанны ничек сакларга мөмкин?

Моны белү өчен без хәзер уен уйнап алабыз.**“Минем фикерем” дигән интерактив уен уздыру.**

Укучыларга түбәндәге сорауларга җавап бирергә тәкъдим итәбез:

-Ватанны ничек сакларга мөмкин?

-Һәркем Ватанны саклауда үз өлешен ничек кертә ала?

-Сез шәхсән үзегез Ватаныбыз өчен нәрсә эшли аласыз?

Һәр укучы үз фикерен белдерә, башкаларның фикерләрен тыңлый, фикер алышуда катнаша.

сорауларга җавап биреп бетергәч, класс дүрт группага бүленә.

Ватанны ничек саклау буенча укучыларга плакат ясарга тәкъдим ителә.

Беренче плакат - “Җаваплы граждан булу”

Икенче плакат – “Патриот булу”

Өченче плакат – “Әзерлекле булу”

Дүртенче плакат – “Бердәм булу”

Укытучы: Бөек Ватан сугышы елларында халкыбыз туган җирен батырларча саклады. Әйдәгез, хәзер Татарстаныбыз батырларын искә төшерик!

Интерактив тактада Бөек Ватан сугышы геройлары турында презентация күрсәтү (М.Җәлил, М.Девятаев, П.Гаврилов һ.б.).

Укытучы геройларның батырлыклары турында кыскача сөйли, укучыларның сорауларына җавап бирә. Бу шәхесләр турында өстәмә материал табарга тәкъдим итә.

VI. Рефлексия

Укытучы: Бүгенге дәрестә без сезнең белән бик күп нәрсәләр турында сөйләштек. Әйтегез әле, сез үзегез өчен нәрсәләр ачтыгыз, нәрсәләрне яңадан аңладыгыз?

Укучыларның җавапларын тыңлау, дәрес буенча фикер алышу.

Дәреснең төп нәтиҗәләрен ясау.

Ватанга мәхәббәт – һәр кеше өчен дә мөһим сыйфат.

Туган илне саклау – һәркемнең изге бурычы.

Ватанны саклау өчен батыр булу гына җитми, ә белемле, эшчән, җаваплы булу да мөһим.

Укытучы: Сез барыгыз да бүген бик актив катнаштыгыз, үз фикерләрегезне белдердегез, бик яхшы җаваплар бирдегез. Рәхмәт сезгә!

VII. Өй эше

Укытучы өй эше бирә:

“Сугыш елларында Татарстан” дигән темага материаллар табарга.

Татарстан турында кызыклы мәгълүмат табып, дәрескә әзерләнергә.

Укытучы: Өй эшен әзерләгәндә сез Татарстан турында күбрәк белерсез, Ватаныбызга булган мәхәббәтегез тагын да арттырырсыз дип ышанам!

VIII. Йомгаклау

Укытучы: Дәресебез ахырына якынлашты. Әйдәгез әле, бергәләп патриотик бер җыр җырлап алыйк!

Укучылар бергәләп татарча патриотик җыр башкаралар (мәсәлән, “Туган тел” / “Туган ягым гөлләр иле” һ.б.).

Укытучы: Шуның белән дәресебез тәмам. Барыгызга да зур рәхмәт! Сау булыгыз!

“Без тынычлык яклы!”

Башлангыч сыйныф укучылары өчен чара

Сәлимова Гөлнара Габделнур кызы,
Шәрипова Зөбәрҗәт Салих кызы,
Алабуга муниципаль
районы ”Иске Юраш урта гомуми белем
мәктәбе”
гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең
I категорияле башлангыч сыйныфлар укытучылары

Максат: - сугыш чоры вакыйгаларын балаларга аңлаешлы итеп җиткерү.

- укучыларнын фикерләү сәләтен ачу.
- өлкән буын кешеләренә ихтирамлылык тәрбияләү.
-укучыларда ярдәмләшеп эшләүне булдыру.

Кереш сүз.

-Язгы ташулар китүгә,барлык җиһан яшелгә төренә.Май ае җитә.Дөнья тагын яшәрә.Никтер бабам бу көннәрдә моңсуланып йөри: “Аның сәбәбе бик зур”,-ди ул...

-Укучылар,бабай ни өчен моңсулана икән,аның сәбәбен әйтә аласызмы?

(9 май-Җиңү бәйрәме!81 ел вакыт үтсә дә,яралар һаман да саклана.Без берни булмагандай,”Ура!”кычкырып,бәйрәм иткәндә,меңләгән ирен,әтисен,улын галтканнар өчен бу көн сызлануларның кабат яңаруы,яралардан кабат кан саркып чыгу көне булып тора.)

-1941 ел, 22 июнь... Таң атып килә. Гүзәл авыллар, шәһәрләр тыныч йокыда. Әниләрнең җылы куенында тәмле төшләр күреп нәни сабыйлар изрәп йоклыйлар. Шул вакытта канга туймас дошман безнең чикләрне бозып, авылларны, шәһәрләрне үлем утына тоттылар. Бөек Ватан сугышы башланды.Бөек Ватан сугышы башлангач бабаларыбыз, Ватанны саклау өчен, яу кырына киткән. Ә авылда хатын-кызлар һәм балалар гына кала. Бөтен эш алар җилкәсенә төшә. Ачлы-туклы килеш барысын да эшләргә туры килә аларга. Ил өчен, фронт өчен дип, көнне төнгә ялгап эшлиләр. Колхоз терлекләрен кararга, урак урырга, ындыр табагында эшләргә туры килә. Ләкин зарланмаганнар, иңнәренә төшкән авыр йөкне җигелеп тарткан алар. Әбиләребез, сугышка киткән ир-егетләребезне алмаштырып, трактор, комбайн штурвалы артына утырган. Җир сөрергә дә, тырмаларга да, чәчәргә дә туры килгән аларга.

Тактада слайдлар күрсәтелә.Укучылар фикер алыша.

Рәшидә әби хәтирәләре(1укучы сөйли)

-Безнең үсмер чакларыбыз нәкъ менә авыр сугыш елларына туры килде. Сугыш башланганда, миңа 13 яшь иде. Әтиемне сугышка алдылар. Авылда эшче көчләр җитешмәгәнлектән, әниләребез әтиләребез эшен алыштырды, ә без, әле яшь кенә кызлар, әниләр белән бергә эшкә йөри башладык. Алар белән көлтә өю, печән чабу кебек эшләрдә эшләдек. Минем буем бик кечкенә иде, көлтә өйгәндә көчем җитми, күтәреп бирергә буем да юк, нишләргә белмичә елый идем. Ә бит фронт өчен, әтиләребез өчен эшлибез, үзебездән өлеш кертәсе килә.

Роза әби хәтирәләре(1 укучы сөйли)

-Әйе, без ул чорда бик күп эшләдек, бервакытта да миннән булмый дип тормадык. Сугыш елларында дару үләннәре җыюның да әһәмияте артты. Мәктәп укучылары һәм пионерлары бу эшнең кирәклеген аңлады һәм аптекага дару үләннәре җыеп тапшырды. Көнозын эшли идек, кайтып чәй эчкәч, арулар беткән кебек була да, без кичке уенга чыгып китә идек. Моны гаепләп тә булмый, без дә бит яшьләр. Арыганлык бөтенләй онытыла. Җырлар, биюләр, уеннар...

Сезгә без кичергәннәрне күрергә язмасын, күгегез һәрвакыт аяз булсын, шулай бәхетле булып яшәгез, яхшы укыгыз, хезмәтне яратып үсегез!”

Укытучы сүзе:

Ак яулыклы татар әбисе!

Син барысын да күрдең: яхшысын да, яманын да. Ләкин син барыбер татар әбисе булып калдың. Ак яулыгыңны башыңнан салмадың. Бүген намаз укыйсың син, сиңа сокланабыз. Тәсбих тотып, илнең иминлеген теләп, балаларыңның саулыгын сорап, Ходайдан ялварасың. Теләгең кабул булсын, и мәрхәмәтле ак яулыклы татар әбисе!

Укытучы сүзе:

-Сугышлар илебезнең төрле почмакларында һаман да бара.Бу сугыш яралары һаман да төзәлми.Әфганистан,Чечен,Украина...

Кешеләр сугыша,кан коя,

Киселә меңнәрчә гомерләр.

Безнең авылда да Әфган сугышында катнашучылар яши.Алар белән горурланырга кирәк.

Укучы чыгышы*:*

-Минем әтием, Әхмәтов Фәрит–Әфган сугышы ветераны.Армия сафларына хезмәт итәргә киткән җиреннән аны сугышка алалар.Ике ел буена ул сугышта була.Күп авырлыклар күрә әтием,ләкин түзем була.Туган авылга исән-имин әйләнеп кайта.Әфганчылар безнең авылда җиде.Мин әтием белән горурланам,аңа охшарга тырышам.

(Укучылар үзләре туплаган материаллар белән Бөек Җиңүгә багышланган газета чыгаралар һәм эшләренә үзбәя куялар)

Укучылар чыгышы.

1 укучы.Май кояшы нигә юмарт дисез,

Бөек җиңү ае ләбаса!

Мәйданнарда мәңгелек ут дөрли,

Ветераннар сафларга баса.

2 укучы.

Сугыш үтте,канлы хәтирәсе

Күңелләрдә калды уелып.

Һәлак булганнарны искә алыйк

Барчабыз да бергә җыелып.

Укытучы:

-Сугыш- газап һәм кайгылар алып килүе белән беребез дә теләмәгән куркыныч бер вакыйга. Безнең бабаларыбыз туган җирне саклау, халкыбызны

фашизмнан коткару өчен зур батырлыкларга бардылар, сугыш кырларында гомерләрен бирделәр. Каһарманлык күрсәтеп вәхшилек, кансызлыкны җиңделәр, Ватаныбызны дошман явыннан сакладылар. Шушы каһарманлыклары — Ватанны саклаганнары һәм илебезгә тынычлык алып килгәннәре өчен мәрхүм сугыш ветераннарын исебездән чыгармыйк.

3 укучы

Без,шәфкать туташлары да,
Озын,авыр юл үтеп,
Солдат гомерләрен саклап,
Берлинга барып җиттек.

4 укучы

Әнә шулай бердәм булып,
Дошманны аттык,кырдык.
Үз өненә кадәр куып,
Җиңү таңын аттырдык!

5 укучы

Ватан гына булсын,
Ватан гына.
Без дә әзер аны сакларга!
Кирәк икән нәкъ бабайлар кебек,
Явыз дошманнардан якларга.

(Укучылар “Һәрвакыт булсын кояш!”җырын башкаралар)

Дәресне йомгаклау. Үзбәя.

Батыр үзе үлсә дә, исеме калыр үзеннән соң килгән буынга!

Максатчан аудитория: 1-4 класс укучылары

Солтанова Лүзия Рәхимҗан кызы,
ТР Актаныш муниципаль районы
"Актаныш беренче урта гомуми
белем бирү мәктәбе" филиалы
“Чөгәнә башлангыч мәктәп-бакчасы”

Максат: 1.Герой шагыйрьнең тормыш юлын күзалларга өйрәнү.

2. Муса Җәлилнең иҗатына карата кызыксыну уяту.

2.Татар халкының герой шагыйре иҗатына патриотик хисләр тәрбияләү.

Җиһазлау: шагыйрьнең портреты, М.Җәлилгә багышланган китаплардан күргәзмә, шагыйрь әсәрләренә иллюстрацияләр, плакатка язылган эпиграф.

Такта алдына ак плакатка эпиграф язып куела.

Батырлык ул –рухи матурлык...Әнә шуңа күрә дә халкыбыз кеше күңеленең рухи бөеклеген югары бәяләгән. Батырларның кылган изге гамәлләре, данлы исемнәре әкиятләргә күчкән, җырларга кергән. Шул олуг батырлык алдында безнең чор кешеләре генә түгел, киләсе гасырларда яшәүчеләр дә башларын иярләр әле...

Минтимер Шәймиев

Класс сәгате барышы.

I.Оештыру.Уңай психологик халәт тудыру.

Бер-беребезгә кояшлы иртә кебек матур кәефләр теләп класс сәгатен башлыйк.

II. Актуальләштерү.

Слайд 1(М.Җәлил портреты)

Бүгенге класс сәгатебез татар халкының бөек улы Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты, патриот шагыйрь Муса Җәлилгә багышлана. Без аны “Батыр үзе үлсә дә, исеме калыр үзеннән соң килгән буынга” исеме астында үткәрербез.

III. Төп өлеш.

Слайд2 (Муса гаиләсе)

1 укучы: (биографиясен сөйли)

1906 нчы елның 15 февралендә Оренбург губернасы, Мостафа авылында Мостафа абый белән Рәхилә апа гаиләсендә кечкенә Муса дөньяга килә .

(укучы сөйләгәндә Мостафа авылы, әти-әниләренең фотосурәтләре эленә)

2 укучы: Ул тиктормас, шук, кызыксынучан бала булып үсә.Башка балалар кебек ул да яланаяк яшел чирәм өстендә йөгергән, казлар көткән, су коенган, әнисенең моңлы җырларын тыңлаган. Гаиләсе ярлы яшәсә дә , Мостафа абый балаларына белем бирергә тырыша. Муса 6 яшеннән авыл мәдрәсәсендә укый башлый. Ул зирәк һәм акыллы укучы була.

3 укучы: Мусаның әнисе нечкә күңелле, ачык йөзле, юмарт җанлы кеше була.

Ул балаларын кече яшьтән хезмәт сөяргә, кешелекле булырга өйрәтә. Рәхимә апа халык җырларын ярата, үзе дә матур итеп җырлый. Шигырьләр, бәетләр, мөнәҗәтләр чыгара.

4 укучы : М.Җәлил үзенең беренче шигырен 13 яшендә яза.Аның тормышы да, иҗаты да балалар белән бәйләнгән. Муса шат күңелле, шаян, тәртипле, тырыш, эшчән балаларны яраткан. Ул үзе дә шундый булган. Балалар өчен шигырьләр, җырлар, уенлы-хәрәкәтле җырлар язган.

-Әйдәгез эле укучылар хәзер аның балалар өчен язган шигырьләрен тыңлап китик.(укучылар чиратлап үзләре ятлап килгән шигырьләрен сөйлиләр)

5 укучы : Муса туып үскән авыл янында гажәеп матур урман җәелеп киткән. Кечкенә Муса анда һәрвакыт күке тавышын тыңларга яраткан. Күкенең моңлы тавышына сокланып ул “Күке” шигырен иҗат иткән.(1 укучы “Күке” шигырен сөйли.-фонограммадан кошлар, күке тавышлары ишетелә)

Ведущий: «В августе 1943 года гестапо напало на след подпольщиков. Мусу Джалиля и его соратников схватили и бросили в берлинскую тюрьму Моабит. Здесь, в камере смертников, ожидая казни, он создает свой бессмертный цикл стихов. Их он передавал сокамерникам, в первую очередь бельгийскому патриоту Андре Тиммермансу.

Эти маленькие, исписанные мелким почерком блокноты, чудом сохранившиеся и вывезенные на Родину, стали главным подвигом поэта. Стихи из «Моабитской тетради» переведены на десятки языков мира».

Чтец 1 (студент):

«Не верь, что я на поле брани пал,
Что сердце перестало биться, нет!
Оно не разожмет свой твёрдый шрам,
Покамест жив на свете хоть поэт.
И в песне той, что родиной дыша,
На родину летит через края,
Не сдержат злобы камни и штыки,
Не задушить огня, что дал Джалиль!»

Ведущий: «Вглядитесь в эти строки. О чем они? О вере, о бессмертии духа, о силе слова, которое сильнее оружия».

Вопросы для обсуждения:

Какие чувства вызывают у вас эти стихи? (Обсуждение).

Как вы думаете, что помогало поэту сохранять мужество в застенках? (Вера в правоту, любовь к жизни, чувство долга, память о семье, о Родине).

Чтец 2 (студент):

(Отрывок из стихотворения «Варварство» или «Чулочки» — самое сильное и трагичное).

Они с детьми погнали матерей
И яму рыть заставили, а сами
Они стояли, кучка дикарей,
И хриплыми смеялись голосами.
У края бездны выстроили в ряд
Бессильных женщин, худеньких ребят...

(После прочтения – короткая пауза)

Ведущий: «Это не просто стихи. Это крик души человека, прошедшего через ад войны и концлагерей. Муса Джалиль был казнен на гильотине 25 августа 1944 года в тюрьме Плётцензее. Ему было 38 лет».

Блок 3: Связь времен. Имя Мусы Джалиля в стенах колледжа (10 мин)

Метод: дискуссия с выходом на профессию.

Ведущий: «Мы учимся в колледже, которому присвоено имя Героя. Это не просто дань истории. Это обязывает нас быть достойными его памяти. Но как мы, будущие учителя, можем проявить мужество сегодня, в XXI веке? Ведь на нас не падают бомбы, нас не пытают в застенках».

Вопрос для дискуссии (работа в микрогруппах или фронтально):

«В чем, по-вашему, заключается мужество современного учителя?»

Ожидаемые ответы (направлять дискуссию):

1. Мужество быть честным: Не врать ученикам, признавать свои ошибки, отстаивать правду, даже если она неудобна.

2. Мужество быть милосердным: Найти подход к «трудному» ребенку, поддержать того, кого травят, не остаться равнодушным к чужой беде.

3. Мужество учиться всю жизнь: Постоянно развиваться, осваивать новое, признавать, что ты чего-то не знаешь, и идти за знаниями.

4. Мужество хранить культуру и язык: Как Джалиль писал на родном языке вдали от Родины, так и учитель в глобальном мире должен сохранять и передавать своим ученикам любовь к родному языку, истории, традициям.

5. Мужество сеять «разумное, доброе, вечное»: В эпоху цинизма и прагматизма учить детей добру, состраданию, честности. Это требует большой внутренней силы.

Ведущий: «Подвиг Мусы Джалиля — это абсолютное, героическое мужество. Подвиг учителя — это мужество ежедневное, будничное, тихое. Но в основе их лежит одно: великая любовь — к людям, к Родине, к своему делу. Имя на стене колледжа — это напоминание нам об этой ответственности».

3. Заключительная часть (5-10 мин)

Ведущий: «Сегодня мы говорили о Мусе Джалиле. Мы поняли, что мужество — это не отсутствие страха, а способность действовать по совести, несмотря на страх. Это верность своим идеалам до конца.

Завершая наш урок, я предлагаю каждому из вас мысленно задать себе вопрос: «А смог бы я? Выдержал бы я такое испытание?» И может быть, ответ будет не важен. Важно то, что этот вопрос заставляет нас задуматься о себе, о своей силе духа, о том, какими людьми мы хотим стать.

Память о героях жива, пока мы о них помним и пока их подвиг вдохновляет нас на добрые дела в нашей собственной жизни».

Рефлексия (один из вариантов):

«Незаконченное предложение»: «После сегодняшнего разговора я понял(а), что мужество для меня — это...»

Минута молчания (в память о Мусе Джалиле и всех павших героях). Объявить: «Давайте почтим минутой молчания память Мусы Джалиля и всех, кто отдал жизнь за свободу и счастье будущих поколений».

(Звучит метроном или тихая торжественная музыка. Минута молчания).

Заключительное слово:

«Спасибо за участие. Помните: вы учитесь в колледже имени Героя. Носите это имя с гордостью и будьте достойны его в своих мыслях, словах и поступках».

"Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге юк"

10-11 нче сыйныфларда ватанпарвәрлек дәресе

Чевачина Розалия Вакыйф кызы,
29 нчы мәктәпнең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

Максат: Әфган сугышы турында белешмә бирү, сугышны китереп чыгарган сәбәпләр, аларны ачыклау, яу кырында башын салган егетләрне хөрмәт белән искә алу.

Хәерле көн, дуслар!

Без бүген сезнең белән ватанпарвәрлек турында сөйләшүне дәвам итәбез. »Әфган сугышы Эхосы" 15 февральдә безнең илдә Ватаннан читтә хезмәт бурычын үтәгән россиялеләрне искә алу көне билгеләп үтелә. Бу дата сугыш хәрәкәтләрендә катнашкан егетләрнең үзләре өчен дә бик әһәмиятле.

Бүгенге сөйләшүгә ачыклык кертер өчен сүзне ерактанрак башлыйк.

Афган уты һаман өтә җанны,
Төшкә кереп, дуслар дәшәләр.
Алар бездән, исән кайтканнардан,
Күктән карап бик көнләшәләр.

Кушымта:
Шәм кабызам, карга чәчәк салам,
Сезне уйлап йөрәк сызлана.
Әрни йөрәк Афганнарда калган
Яп-яшь гомерләрне кызгана.

Көнләшмәгез дуслар, сезне уйлап
Үрсәләнә йөрәк, кан сава.
Карга салган розаның энәсе
Йөрәкләргә барып кадала.

Мәчетләрдә дога, чиркәүләрдә
Сезнең хакка шәмнәр куелган.
Исемегез безнең йөрәкләрдә
Онытмаслык итеп уелган.

Географик хәленә килгәндә, Азияның коньяк-көнбатышына урнашкан. Диңгезгә чыгу юлы юк. Чикләренең гомум озынлыгы 5529 чакрым. Төньяк-көнчыгыштан Кытай һәм Һиндстан белән, көнчыгыш һәм көньяктан Пакистан; төньяктан Таджикстан, Үзбәкстан, Төркмәнстан; көнбатыштан Иран белән чиктәш.

Илнең 4/5 өлешен таулар били. Җирләре комлы, ташлы. Климаты коры. Биек таулар да кыш 7-8 аи дәвам итеп таулар да кар ятса, җәен температура + 50* ка җитә.

Җир асты байлыклары: төсле, кыйммәтле, сирәк һәм кара металлар, нефть һәм газ.

Ил башлыча - аграр.

Халыкның 1/7 өлеше күчмә һәм ярымкүчмә тормыш алып бара, терлекчелек белән шөгыльләнә. Гомум мәйданның 13 % ы гына сөренте җирләр .

Сәнәгать(промышленность) алга китә алмаган, санаулы гына туку, мебель

ясау, цемент җитештерү предприятияләре бар. Йон келәмнәрне кустар рәвештә җитештерү үсеш алган .Әфганстан-дөнья базарына каракуль тиреләрен чыгару буенча танылу алган. Тимер юллар юк, төп транспорт төрләре - автомобиль, һава юлы, ишәк һәм дөяләр.

Әфганстан - күпмилләтле дәүләт.Үзе белән чиктәш булган барлык илләрнең дә милләт вәкилләре яши. Ирләрнең уртача гомер озынлыгы 46, хатын-кызларныкы 44 яшь. Халыкның 80%ы авылларда яши, 70% халык надан. Укыган кеше зур хөрмәткә ия. Әфганстан халкының бүгенге көндәге яшәү рәвеше урта гасырлардан бик аз аерыла.Ислам динен тоталар, аның гадәтләренә, таләпләренә буйсыналар. Әфганстан халкы гаять кунакчыл халык, кунакны ихтирам итәләр; түрдәге урын да, ризыкның иң татлысы да аның өчен һәм шул ук вакытта үчле дә халык. Кем дә булса аңа зыян сала икән, ул аны онытмый, кичерә алмый һәм бу үчнең буыннан - буынга дәвам итүе дә мөмкин. Гомумән, әфганлылар, "кунак ашы - кара-каршы" дип яшәүче халык, яхшылык өчен дә, начарлык өчен дә. Безгә таныш булмаган Әфганстан иле турында кыскача шулар.

"Кара тюльпан -кайгы хәбәре"

Әйе, бу дәһшәтле сугышта күпме кан, күпме күз яше түгелгән. Шуңа да бүген без Әфганстанда батырлык күрсәткән яугирләрне хөрмәт итәргә һәм Ватан өчен гомерләрен биргәннәрнең якты истәлеге алдында баш иергә тиешбез. "Көт, әнием, кайтырмын !" дип хатлар язган 13 мең 833 ир - егетнең Әфганстанда гомере өзелде, 49 мең 985е гарипләнде ."200 нче № лы йөк " төягән самолетларда безнең Кама Тамагы районына да 5 табут кайтты. Һәм тагын «ни өчен?» дигән сорауны кабатларга мәҗбүр булабыз.

XX гасыр - дөньяда күп үзгәрешләр гасыры. Алда әйтелгәнчә, Әфганстанда үзгәрешләр булмады диярлек. Бу ил феодализм шартларында яшәвен дәвам итте.

1973 елда илдә переворот булды һәм ил республика дип игълан ителде .Власть башына Мөхәммәд Дауд килде. Ә 1973 елга кадәр, 1965 нче елда ук , Әфганстанда халык - демократик партиясе оештырылды. Бу партиянең максаты - илне социалистик юлдан алып бару була. Әмма әфган армиясының бер өлеше үзен ил Президенты дип игълан иткән М. Даудка буйсынмый башлый. Халык - демократик партиясе лидерларыннан берсе Хафизулла Әмин җитәкчелегендәге танк частьлары М. Дауд сарайларын басып алып туганнары белән бергә аны үтерә . Шушы хәрби переворот - власть алышыну Әфганстанда "Апрель революциясе " дип игълан ителә дә инде . (1978.27.04)

Революция лидерларының максаты: илдә социализм урнаштыру һәм динне бетерү. Яңа режим әфган халкында бик аз яклау таба һәм каршылыкларга очрый. Халык яңа режимга каршы баш күтәрә. Яңа хөкүмәт Советлар Союзына үз халкын бастыру өчен хәрби ярдәм сорап мөрәҗәгать итә. Феодализм шартларында яшәгән Әфганстан мәсьәләләрен социалистик юл белән хәл итәргә әзер түгеллеген безнең ил җитәкчеләре аңлый. Анда дин көчле, халык надан, икъдисат артта калган. Халык якламаган хөкүмәтне штыклар ярдәмендә генә саклап алып калып буламы соң? Әфганстанның власть башлыклары да (Тараки һәм Хафизулла Әмин) уртак фикердә була алмыйлар. Әфганстан лидеры Хафизулла Әмин Мәскәүдән хәрби ярдәм сорап кат-кат мөрәҗәгать итә. Озак

икеләнүләрдән соң, декабрь аенда,(1979) Совет гаскәрләрен Әфганстанга кертү турындагы карар политбюро утырышында кабул ителә. Серле була ул документ: "Дәүләт чиген кисеп чыгу вакыты 15.00 сәгатъ." дип языла . Менә шушы көн - 1979 елның 25 декабреннән башлап илебез тарихының батыр һәм бер үк вакытта оятлы да бите ачылды. "Күрше дус халыкка интернациональ ярдәм күрсәтү" дигән сүзләр астында 18-20 яшьлек егетләрнең гомерләре өзелде. 1980 елның гыйнвар аенда илгә 50 меңгә якын кешедән торган Совет гаскәрләре кертелә. Кыскасы, халык революциягә, яңа режимга риза булмыйча баш күтәрә, ә хөкүмәт башлыклары, халыкны бастыру очен Советлар Союзыннан хәрби ярдәм сорый. Менә шулай башлана безнең халык телендәге "әфган сугышы". Ә Совет гаскәрләрен керткәч, хәл тагын да кискенләшә. Әфган оппозициясе моңа каршы килеп кенә калмый, үзе безнең чикне бозып, диверсияләр оештыра. 1981 елда чик сакчыларын камап алу, шартлаткычлар, корал, наркотиклар кертү көчәя. Ә 1982 елның башыннан совет җитәкчелегенең карары белән Әфганстанның бөтен чиге буенча 100 чакрымга кадәр кереп хәрби хәрәкәтләр башлана.

Кирәк идемени бу гаделсез сугышта арысландай ир -егетләребезнең чәчкә кебек гомерләрен өзү ? - дигән сорау бүген дә җавапсыз кала.

уган жирен,илен сакларга дип
Газиз улын ана озата.
Берни булмас,эни ,кайгырма дип
Ана кунелен улы юата.

Чечен жирен саклый безнен солдат
Э алары чэчк саталар.
Чэчэклэрдэй матур улларыбызЯраланып илгэ кайталар...

Кемгэ кирэк жирнен байлыклары,
Илне булэ байлар,турэлэр.
Хезмэткэ дип киткэн улларыбыз
Бер гонахсыз кое улэлэр...

Кемгэ кирэк байлык шул сугышсын
Солдат бары илне сакласын.
Туплар шартлап тотен капламасын,
Кояш нуры жирне яктыртсын!!!

Еллар үтү белән күп вакыйгалар хәтердән җуела . Әмма без бу гаделсез сугышның корбаннарын онытырга тиеш түгелбез. Үлгәннәр хәтере исәннәрдә яши. (Бер минутлык тынлык игълан ителә.)

"Без бу җирдә туып үскәннәр "

Әфганстанның шомлы җилләре безнең Олы Салтык авылын да урап үтмәде. Безнең авылда туып үскән егет ул дәһшәтле көннәрнең шаһиты булып, гомерләрен куркыныч астына куеп ут астында йөрергә, дары исен иснәргә туры килә. Хәрби хезмәтен Әфганстанда үткән бу солдатка исән - сау туган якларына әйләнеп кайтырга насыйп була.

Яруллин Илшат Вәлиәхмәт улы

Хөрмәтле укытучылар һәм укучылар! Безнең барыбызның да теләк бер - Җир йөзендә сугыш утлары кабынмасын. Яшь егетләрнең гомере вакытсыз өзелмәсен, ата -аналар кайгы яше түкмәсен иде. Солдат сугышны үзе сайламый, ул сугышны игълан итми. Фәкать ул кушылган боерыкны үти. Меңәрләнгән корбаннар, күз яшьләре, гариплекләр китергән сугыш өчен солдат гаеплеме, үз җирендә үзе хуҗа булган әфганлымы ? Әллә халык язмышы белән уйнаган ил башлыкларымы? Бу тема озак еллар яшерен булып кала килде. Әфган сугышы барлык милләт кешеләре өчен дә уртак. Һәр шәһәр, район, авылга кагылган аның рәхимсез җиле. Күп йортларга кергән аның кайгысы. Бу афәт күпме яшь гомерләрне өзде, әти-әниләренә гомерлек кайгы китерде. Исән-сау кайтучылар бәхетле, тик шулай да аларның да матур еллары сугышта үткән, ул көннәр тормышларында иң авыр хатирәләр булып калырлар.

Сугышта катнашучылар гына түгел, без, бүгенге яшьләр, һәм киләчәк буын кешеләре дә бу вакыйганы онытырга тиеш түгел. Көннәр тыныч, күкләребез аяз булып, атыш, шартлау тавышларын ишетмичә яшәргә язсын иде. Киләчәктә җир йөзендә сугышлар кабатланмасын иде.

Ватанпарвәрлек темасына Түбән Кама шәһәренең 29 нчы гомуми урта белем бирү мәктәбеннән интервью

Безнең татар халкында бик матур бер мәкаль бар: “Ятып калганчы, атып кал”. Шушы мәкальгә таянып, без дә тәвәкәлләргә булдык әле, җәмәгать. Сыйныфыбыз белән уйлаштык та, мәктәп күләмендә интервью үткәрергә булдык.

Без, 9 нчы б сыйныфының барлык җиргә дә “борынын тыгарга” яратучы берничә егете һәм дә үзем,кызыксынуыбызны җиңә алмыйча, төрле сыйныф укучылары белән әңгәмә оештырырга планлаштырдык. Юкны бушка аударырга күнекмәгәнбез, кабинет бетереп йөрүебезнең сәбәбе дә бик җитди: җәмәгатьчелек белән саф татар телендә аралашу, безне кызыксындырган төп сорауга җавап табу. Төп коралларыбыз - кәгазь, каләм, фотоаппарат һәм яхшы кәеф. Әйе, берничә көн журналист ролендә булып карыйк әле. Билгеле инде, “чиле - пешлерәк” журналистлар, ә шулай да...

Маршрутыбыз – 9-10 нчы сыйныфлары белән башлана һәм мәктәбебезнең “йөзек кашы” 11 нче “А” да тәмамланачак.

1нче тукталышыбыз - “9 нчы А” сыйныфы

- Хәерле көн! Без бүген “Армиягә барабызмы?” соравына җавап эзлибез. Үзегез белән таныштырып китегез әле.

- Мин – Сираев Кәрим, 9 нчы елымны үз мәктәбемдә белем алам. Сезнең соравыгызга бик теләп җавап бирәм: “Мин киләчәктә үземне хәрби итеп күз алдыма китерәм. Бу минем кече яшьтәге хыялым. Үз илемә кирәкле кеше булып, файда китереп яшәргә исәп! » Калганнар тыныч кына утырганда, Элина исемле кызыбыз үз фикерен безгә җиткерергә ашыкты: “Ә мин кеченәдән полиция хезмәткәрләре турында фильмнар карап үстем. Минем фикеремчә, бу һөнәр ияләре тәвәкәллек, гаделлек, батырлык кебек сыйфатларга ия булырга тиеш.

Әнием кечкенәдән миндә ныклы характер тәрбияләде һәм бүгенге көндә мин полиция хезмәткәренә белем алу өчен тулысынча әзер!”

-Әйдәгез, дусларым, яшьтәшләребезгә рәхмәт әйтеп, аларга киләчәктә уңышлар телик!

Сәяхәтебезне дәвам итәбез һәм без үзебезнең яраткан кабинетыбызда.

Без этнокультура сыйныфында белем алабыз, шуңа күрә кечкенәдән үк телебезнең байлыгына сокланып, татар әдипләренең иҗаты белән кызыксынып үстек. “Армиягә барабызмы?” дигән сорауга, без, берсүзсез, “Әлбәттә!” – дип җавап бирәбез, чөнки без - Җәлилләр, Алишлар, Кутуйлар үрнәгендә тәрбияләнеп үскән егет-кызлар! Менә шул урында сезгә үземнең армия темасына кагылышлы шигыремне тәкъдим итү урынлы булыр дип уйлыйм.

Сезгә әйтер сүзем бар (татар кызының Муса Җәлилгә мөрәҗәгате)

Муса абый, сезгә генә
Әйтер сүзем күбәйде.
Кайсысыннан башлыйм икән,
Кайсысы иң кирәге?
Нигә икән бу егетләр
Армиягә китмиләр?
Хезмәт итәргә кирәген
Әллә алар белмиләр?
“Ир-егетләр-ил тоткасы”-
Дигән сүзләр хак микән?
Акыллы, кыю егетләр
Кай җирдә яши икән?
Сыра белән томаланган
Күбесенең акылы,
“Компьютер”дип җенләнә
Егетләрнең “асылы”.
Йөрәк әрни, Муса абый,
Кем безне яклар икән?
Алай-болай сугыш булса,
Безне кем саклар микән?
“Алла үзе сакласын”,-дип
Теләргә генә кала,
Сезнең кебек егетләр юк,
Кем безне яклый ала?
Муса абый, кайда соң ул
Сезнең кебек егетләр?
Кыю, батыр һәм намуслы
Ныклы корыч кебекләр.
Заманадан артта калган
Тиле кыздыр мин, бәлкем,

Шагыйрь абый, соравыма
Җавап бирер икән кем?
Гыйләҗева Нурзилә

- Менә шулай ижади тукталыш ясаганннан соң, сыйныфларга да юл тотабыз. Интервью барышында төрле фикерләр ишетергә туры килде, бәхәсләшеп тә алдык. Күп кенә егетләребез сәламәтлекләреннән зарландылар, “Гел хастаханә юлында йөрергә туры килә”, - дип үз борчулары белән уртаклаштылар. Әңгәмә барышында кайбер егетләрнең әти-әнисе армия хезмәтенә каршы икәнлеге дә ачыкладык.

Ә хәзер мәктәбебезнең “йөзек кашы” булган 11 нче а сыйныфына юл тотабыз. Бу сыйныфта кызлар күбрәк икән, ә егетләр монда “дефицит». Шулай да, без үзебезне кызыксындырган сорауга җавап таптык, дуслар. Күп егетләр армиягә барырга әзер, ләкин югары белем алу-аларның төп максаты. 11 нче сыйныфны тәмамлаган егетләребез, инженер, инглиз теле укытучысы, табиб, it-белгечләр булырга хыялланалар. Без аларга киләчәктә бары тик хыялларының чынга ашуын теләп калабыз!

Сәяхәтебез ахырына якынлашты. Дәрес-дәрес инде ул. Ә менә тормыш казанында кайнап, мәшәкатьләр эчендә югалып калмыйча, үз туган телеңдә иркенләп сөйләшеп, сайлаган һөнәреңә, трмышка, хыялларыңа тугры булып яшәү-үзе бер бәхет. Безнең фикеребезчә, үзебез оештырган бу чара бик кызыклы һәм файдалы. Интервью барышында без күп мәгълүмат алдык, бер-беребезгә файдалы киңәшләр бирдек, тормышның бер агымында йөздек.

Непокоренное сердце: Жизнь и подвиг Мусы Джалиля. Урок мужества.

Целевая аудитория: ученики 6 класса

Шакирова Ильмира Минсаитовна,
учитель английского языка 1 квалификационной категории
Шафигуллина Альбина Баязитовна,
учитель английского языка 1 квалификационной категории,
МБОУ «Гимназия №11 г. Лениногорска»

Форма проведения: Бинарный интерактивный урок.

Цель: Формирование у учащихся представлений о героизме, патриотизме и силе человеческого духа на примере жизни и творчества Мусы Джалиля.

Задачи:

Образовательные: Познакомить учащихся с биографией Мусы Джалиля, историей создания «Моабитских тетрадей».

Развивающие: Развивать критическое мышление, эмоциональный интеллект, навыки выразительного чтения и работы в группе.

Воспитательные: Воспитывать чувство гордости за героев войны, уважение к памяти предков, желание сохранять историческую правду.

Планируемые результаты (УУД):

Личностные: Осознание ценности жизни, понимание смысла понятий «мужество», «честь», «долг».

Коммуникативные: Умение слушать собеседника, аргументировать свою точку зрения.

Познавательные: Умение извлекать информацию из текста, аудио и визуальных источников.

Ход классного часа.

I. Организационный момент и мотивация (3 минуты)

Учитель стоит у стола, на котором стоит «Черный ящик».

Учитель 1: Здравствуйте, ребята! Сегодня у нас необычный классный час. Перед вами «Черный ящик». В нем лежит предмет, который пережил войну, прошел через тюремные камеры, видел смерть, но сохранил жизнь. Как вы думаете, что может быть сильнее смерти?

(Вероятные ответы детей: память, слово, любовь, вера).

Учитель 1: Верно. А в этом ящике — тетрадь. Но не простая. Это свидетельство невероятной силы духа человека, который даже в цепях оставался свободным. Сегодня мы поговорим о поэте, герое, патриоте — Мусе Джалиле.

Учитель открывает ящик, достает старую тетрадь.

II. Биографический квест «Линия времени» (10 минут)

На экране демонстрируется видеоролик с биографией поэта до 3.30 сек. (https://rutube.ru/video/55a1e8a2c3009474e6e73166f24def86/?utm_source)

Задание: На доске нарисована временная шкала (1906 – 1944).

Учитель 2 раздает ученикам карточки с событиями. Ученики выходят к доске и прикрепляют событие в правильный год или период.

Карточки с событиями:

1906 г. — Родился в деревне Мустафино.

1930-е гг. — Стал известным поэтом, руководил Союзом писателей Татарии.

1941 г. — Ушел на фронт военным корреспондентом.

1942 г. — Был тяжело ранен и попал в плен.

1942-1943 гг. — Находился в концлагере «Моабит», создал подпольную группу.

1944 г. — Казнен в Берлине. Посмертно присвоено звание Героя Советского Союза.

Учитель 2: Обратите внимание, ребята. Муса Джалиль мог бы просто ждать конца. Но он выбрал борьбу. Даже в неволе он организовал подпольную группу среди военнопленных. Он понимал: слово тоже может быть оружием.

III. Постановка темы: «Моабитские тетради». (10 минут)

1. Учитель 1: В тюрьме Моабит у Джалиля не было бумаги. На чем он писал стихи? (Дети высказывают свои предположения)

Учитель 1: На обрывках бумаги, на полях книг, иногда просто запоминал наизусть и передавал товарищам. Две маленькие тетради чудом сохранились и были возвращены на Родину после войны. Их назвали «Моабитские тетради».

2. Аудио фрагмент: Включается запись стихотворения «Варварство» (отрывок). (Текст стихотворения на слайде презентации).

3. Интерактивное упражнение «Ассоциативный куст»:

На доске написано слово «МУЖЕСТВО»

Учитель 2: Ребята, какие качества помогли Мусе Джалилю не сломаться? Выйдете к доске и допишите их вокруг слова.

(Возможные ответы: Верность, Любовь к Родине, Талант, Дружба, Надежда, Память, Гордость).

IV. Творческая мастерская «Слово, которое живет». (10 минут)

Дифференцированное задание. Класс делится на две группы.

Группа 1. «Письмо в прошлое».

Учитель 1: Напишите короткое письмо Мусе Джалилю (3-4 предложения). Что бы вы хотели ему сказать? За что поблагодарить? Пример: «Уважаемый Муса! Спасибо за ваши стихи. Мы помним ваш подвиг...»

Группа 2. «Цветок памяти».

Учитель 2: На красной бумажной гвоздике (символ памяти) напишите одно слово-качество, которое, по вашему мнению, должно быть у современного героя. Приклейте гвоздики на ватман.

На доске размещен ватман с нарисованным стеблем.

V. Домашнее задание (2 мин)

Домашнее задание (на выбор, дифференцированное):

Базовый: выписать 3 цитаты из стихов Джалиля, которые показались самыми сильными.

Повышенный: Подготовить мини-презентацию (3-4 слайда) «Муса Джалиль и современность»: почему его творчество актуально сегодня?

VI. Рефлексия и Заключение (10 минут)

Прием «Микрофон»: Учитель передает символический микрофон. Каждый желающий может закончить фразу:

«Сегодня я понял, что мужество — это...»

«Для меня этот урок важен, потому что...»

«Я запомнил, что...»

Учитель 2: «Моабитские тетради» были найдены бельгийским адвокатом Андре Тиммермансом, который рисковал жизнью, чтобы сохранить их. Это значит, что подвиг Джалиля объединил людей разных национальностей против зла.

Учитель 1: Муса Джалиль писал: «Жизнь измеряется не годами, а делами». Сегодня мы увидели, как одно человеческое сердце, наполненное любовью к Родине и верой в справедливость, может стать примером для поколений. Его слово не умерло — оно живёт в наших сердцах, пока мы помним.

Звучит стихотворение «Праздник матери». Исполняет И.М. Шакирова, учитель МБОУ «Гимназия №11 г. Лениногорска», победитель Муниципального конкурса МО «Лениногорский муниципальный район» «Джалиловские чтения».

"Батырлар даны". Батырлык дәресе.

Целевая аудитория: 5 сыйныф укучылары

Шарипов Рафил Камил улы,
Алабуга муниципаль районы

Максат. Патриотик хисләр үстерүгә ярдәм итү:

1.Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау;

2.Күмәклек, иптәшлек, үзара ярдәмләшү, ижади фикерләү тәрбияләү; 3.Патриотизм, тарихи хәтер, сугышка нәфрәт тәрбияләү.

Алып Баручы: Игътибар! Игътибар! Иске Юраш мәктәбе сөйли һәм күрсәтә! Бүген Бөек Җиңү көненә багышланган сыйныф сәгате спорт залында узачак.

«Юлга» маршы астында, залга балалар керә .

Алып баручы: Быел без зур бәйрәм-Бөек Җиңүнең 81 еллыгын билгеләп үтәбез. Бу бәйрәм бер үк вакытта күңелле дә, моңсу да. Шунысы куанычлы, безнең солдатлар җирдә тынычлыкны саклап калдылар. Кызганыч, чөнки Ватаныбыз азатлыгы өчен барган сугышларда алар күп һәлак булды. Алар безнең яхшы, бәхетле илдә яшәвебезне теләделәр. Бу дәһшәтле сугышны кичерүчеләр саны бик аз инде. Бүген без, данлы бабаларыбызның нәсел-нәсәпләре көчле, җитез, оста һәм һәрвакыт Ватанны сакларга әзер булуыбызны күрсәтү өчен җыелдык.

Алып баручы: Без тату спорт командаларын сәламләвебезгә шатбыз.

Бүген бездә кунаклар, безнең нәтиҗәләрне хөрмәтле жюри бәяләячәк:

1. …..
2. ….

Алып баручы: һәр җиңү өчен команда йолдызчык алачак. Кемнең командасы күбрәк йолдызлар ала, шулар җиңәчәк тә. Тырышыгыз, балалар. Барыгызга да уңышлар телим.

Командалар сәламләве

Команда капитаны: **безнең команда**
Бергә: **«Моряклар»**
Команда капитаны: **безнең девиз**
Без- моряклар
Мускуллар нык!
Океан һәм диңгездә
Бездән көчлеләр юк!

Команда капитаны: **безнең команда**
Бергә: **«Танкистлар»**
Команда капитаны: **безнең девиз**
Бер, ике, өч-
Бездә бардыр көч!
Танкистлар, алга!
Илне сакларга!

Алып баручы:

Кирәкми безгә кан кою,
Кирәкми безгә сугыш!
Безнең теләк якты, матур,
Тыныч хезмәт һәм тормыш.

Бүген без сезнең белән курку белмәс разведчикларыбызның батырлыгын искә төшерербез. Алар үз тормышлары бәрабәренә дошманның мәкерле планнары турында мөһим мәгълүматлар таба.

Эстафета 1. “Батыр разведчиклар”

Катнашучыларга пилотка кияргә һәм кулына автомат алырга кирәк. Аннары шуышып билгеле урынга кадәр барырга һәм кире кайтырга. Пилотка һәм автоматны киләсе катнашучыга тапшырырга.

Алып баручы:

Борчылмагыз! Үсеп килә
Батырларның оныклары.
Бабайларның батырлыгын
Бер малай да онытмады.

«Барысы да фронт өчен, барысы да җиңү өчен!" Ул кырыс елларда ил шундый лозунг астында яшәде. Хәрби заводларда, басуларда өлкәннәр дә, үсеп килүче балалар да эшләде. Үз хезмәтләре белән алар фашистларны җиңүгә якынайттылар. Ватаныбызга тагын ни белән ярдәм итәргә була? Балалар фронтка посылкалар җыйдылар. Мондый посылкага нәрсә сала алыр иде? (Балаларның җаваплары) солдатларга җылы - җылы әйберләр: оекбашлар, бияләйләр, шарфлар кирәк иде. Тагын нәрсә? Хатлар язу өчен кәгазь, юынырга сабын, әлбәттә инде, җиңү теләп хатлар салдылар.

Эстафета 2. “Посылка җый”

Балалардан (3-5 м) арада өстәлдә төрле әйберләр ята: оекбашлар, бияләйләр, шарфлар, хатлар өчен кәгазь, сабын, хатлар. Һәр команда янында посылка тартмасы тора. Балалар чиратлап кирәкле әйберләрне алалар, тиз һәм пөхтә тартмаларга салалар. Биремне үтәгән беренче команда җиңә.

Алып баручы:

Солдат сугыш кырларында
Яраланып калса әгәр,
Хәрби табиб коткарачак,
Килер бары яхшы хәбәр.

Сугыш вакытында солдатлар төрле авырлыктагы яралар алдылар, шәфкать туташлары аларны сугыш кырыннан алып чыктылар. Еш кына алар нәзек, әле генә мәктәпне тәмамлаган яшь кызлар иде. Өмет белән аларны сугышчылар “сестричка”дип атадылар. Күпме солдатның гомерен саклап калды алар…

Эстафета 3 “Беренче ярдәм”

Командадан 2әр кыз һәм 1 малай катнаша. Малай - яралы, кызлар аңа ярдәм итәргә ашыгалар. Урындыкка утырталар һәм кулын бәйләп, косынкага эләктерәләр, икесе ике ягыннан тотып кире алып киләләр.

Алып баручы:

Булмасын ул, булмасын,
Кирәкми безгә сугыш!

Булмасын бер куркыныч,
Булсын бөтен ил тыныч!

Солдат өчен иң мөһиме-аның коралы, патроннары, гранатлары. Кыскасы, сугыш кирәк-яраклары! Солдатларга алар бик күп кирәк иде, шуңа күрә сугыш вакытында солдатлар бер-берсенә булыштылар, снарядлар алып килделәр.

Эстафета 4. «Сугыш кирәк-яраклары белән тәэмин ит»

Балалар бер кулларына граната, икенче кулларына снаряд тотып, билгеле урынга кадәр, каршылыкларны сикереп уза, ящикка алып барып сала, кире йөгерә. Бу биремдә тизрәк, тупларны аз югалтулар белән алып барачак команда җиңә.

Алып баручы:

Сугыш килде безгә сорамыйча
Шакымыйча керде ишектән,
Кабатладык шунда тешне кысып
“Без җиңәргә тиеш ничек тә!”

Меңләгән солдатны авыл халкы азык – төлек белән тәэмин итеп торды, армиягә, илгә бик күп икмәк, ит, сөт, яшелчә, бәрәңге тапшырды.

Эстафета 5. “Азык-төлекне фронтка илт” Һәр командага зур йөк машинасы бирелә. Зур савытта азык-төлек макетлары: сөт, икмәк, консервлар һәм башкалар бар. Һәр укучы берәр генә эйбер ала.

Алып баручы: Бер кайтмасак, бер кайтырбыз дип китсәләр дә, күпме авылдашларыбыз туган туфрагын күрү бәхетенә ирешә алмады. Алар ераста мәңгелек йокыга талдылар. Туган җирләре өчен башларын салган бу батырларны онытырга безнең хакыбыз юк, һәрберебезнең күңелендә алар мәңге саклансын!

Эстафета 6. “Төз атучы”

Балалар тупны сикертеп алып баралар, кыршау эченә кереп басалар, тиешле урынга тупны аталар, тупны кире сикертеп алып килеп, икенче кешегә тапшыралар.

Алып баручы:

Җиңү көне җиңел бирелмәде,
Җыр җырланмый шөһрәт-дан өчен.
Йөрәк җылый һәрбер солдат өчен,
Егермеләп миллион җан өчен.
Яңгыра җыр, тыйнак илем өчен,
Рәхмәт, Ватан, җиңдең, талпындың.
Яңгыра, җыр, горурлыгы булып халкымның.
“Катюша” җыры башкарыла

Алып баручы: командалар арасындагы ярышлар менә инде ахырына якынлаша.

Бик тату уйнадыгыз, биремнәр үтәдегез. Йолдызчыкларны да санарга вакыт.

Сүз жюрига бирелә.

Дошманга каршы язучылар, шагыйрьләр да сугышкан. Ватанны якларга дип каләм ияләре үз иреге белән фронтка китә. Каләмне мылтыкка алмаштырып, фронтның иң алгы сызыкларында сугышып, ил өчен һәлак булучылар күп. Фатих Кәримнең сугышка керер алдыннан язган шигырен тыңлап китик.

Алып баручы:

Рәхмәт Сезгә, батыр ветераннар,
Саклап калган өчен илебез.
Мәңгелек дан Сезгә, каһарманнар,
Тыныч булсын җир һәм күгебез!

Барлык бала дөньяда бәхетле яшәсен өчен солдатлар Җирне, күкне, тынычлыкны саклый. Бүгенге бәйрәм һәр кешенең ишеген ачып керә һәм үзе белән шатлык алып килә! Барыгызны да Бөек Җиңү бәйрәме белән! Батырларның данын оныклары зурлый!

“Җиңү көне” җыры яңгырый.

Балаларга медальләр тапшырыла: “Яшь танкист”, “Яшь моряк”

Тере тарих. Батырлык дәресе.

8-11 класс укучылары

Ямалиев Марсель Василович,
Ямалиева Дәлилә Шамиловна,
Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесе «Шәдче урта гомуми белем бирү мәктәбе»

Максат: Яшь буынны патриотик рухта тәрбияләү - мөһим юнәлеш. Чөнки кешелекнең киләчәге, Ватан язмышы, гаилә бәхете киләчәктә гражданин булачак нәни баланың бүген нинди тәрбия алуына бәйле.

Бурычлар: Бүгенге көндә безнең алда торган мөһим бурычларның берсе – тормышка әзер булган, үз Ватанына чын күңелдән бирелгән Кеше, Гражданин һәм Патриот тәрбияләү. Патриотик тәрбия дигәндә, без балаларны милли үзаңга һәм гражданлык хисенә ия булган шәхесләр, Ватанның лаеклы уллары һәм кызлары итеп тәрбияләүне күз алдында тотабыз. Патриотлык - үз иленә, туган җиреңә, халкыңа, табигатькә, милли традицияләргә, мәдәнияткә мәхәббәт ул.

Шул максаттан чыгып, мәктәптә тәрбия системасы укучыларда милли тарихыбызга, туган телебез һәм әдәбиятыбызга, мәдәниятебезгә мәхәббәт тойгысы, үз халкың белән горурлану хисләре, аның тарихын, уңай гореф – гадәтләрен, традицияләрен өйрәнү белән кызыксындыру шикелле сыйфатлар булдыруны күз алдында тотарга тиеш.

Укучыларны патриотик рухта тәрбияләү буенча класстан тыш чара.

Россия турында патриотик ролик карыйбыз. (Ролик күрсәтелә)

Укытучы: Сез бу видео роликны карагач нинди хисләр кичердегез?

Укучылар:

а) Туган ил белән горурландык.

б) үзебезнең спортсменнар өчен шатландык

в) беренче космонавт Юрий Гагарин безнеке

г) безнең армия бик көчле

д) сугышта җиңгән бабаларыбыз белән горурландым.

Укытучы: Димәк без сезнең белән бүген Туган илне ярату, ватанчылык турында сөйләшәбез. Ә сез, укучылар, Патриотизм сүзен ничек аңлыйсыз?

Укучылар:

а) ул үз илеңне ярату

б) Ватанны ярату

в) халкыңны ярату

г) үз илең өчен көрәшкә әзер тору

д) тормышка әзер булу

е) үзенең туган җиреңне ярату

з) туган табигатьне ярату

и) милли традицияләргә ярату

к) туган телгә мәхәббәт

л) гайләңне ярату

м) мәктәпне, иптәшләреңне ярату.

Укытучы: чыннан да Патриотизм (ватанпарвәрлек) – грек сүзе, - ул үз илеңне, халкыңны өзелеп ярату һәм үз Ватаның өчен армый – талмый көрәшергә әзер торуны аңлата.

Укытучы: ә хәзер мин сезгә күренекле шәхесләрнең патриотизм турында әйткән сүзләрен күрсәтеп китәсем килә.

"Патриотизм: синең илең башкаларныкыннан яхшырак дигән фикер, чөнки нәкъ менә син анда тугансың». Бернард Шоу.

"Ватаның синең өчен нәрсә эшли ала, дип сорама, туган илең өчен нәрсә эшли аласың, дип сора». Джон Кеннеди.

"Патриотлык-Ватанга, үз халкыңа мәхәббәт, тугрылык һәм бәйләнгән булу». Д. Н. Ушаков. Рус теленең төпле сүзлеге.

Укытучы: укучыар бер легенданы тыңлагыз әле. Шәһәр озак вакыт чолганышта тора. Дошманга каршы торучы шәһәрдә су һәм ашамлык калмады, ә кешеләр арыганлык һәм ачлыктан егылды. Көтмәгәндә җимерек шәһәр диварында бер карт пәйда булды. "Әгәр сезнең арада, - дип мөрәҗәгать итте ул газапланган кешеләргә, үзенең бердәнбер улын бу дивар стеналарына катырып куярга ризалашкан әни табылса, дошман шунда ук чигенәчәк". Һәм әнисен шундый адымга барырга күндергән яшүсмер табылды. Яшүсмерне станага катырып куйдылар, дошман чигенде. Гасырлар узды. Әмма кешеләр бу легенданы гасырлар буе сөйлиләр, чөнки ул әхлакый-рухи байлык, хисләр тирәнлеге, Ватанга чиксез мәхәббәт һәм әхлакый чисталык булып кала.

Укытучы: Патриотизм турында күп сөйләргә була. Безнең илебездә патриотлар бик күп. Ә бүген без сезнең белән үзебезнең төбәк турында гына сөйләшербез. Безнең мәктәптә музей эшләп килә. Төбәгебезнең геройларын сез беләсез. Ләкин бүген сүзне башкарак юнәлештә алып барырбыз.

Хәзер, укучылар мин сезгә бер һәйкәл күрсәтәм. Сез бу һәйкәл турында нәрсә беләсез? Сезнең бу һәйкәлне күргәнегез бармы?

Укучылар:

- Бу һәйкәл Мамадышта урнашкан.

- Ул улларын сугышта югалткан аналарга багышлап төзелгән.

Укытучы: Ә хәзер “Аналарга мәңгелек дан” һәйкәле турында без Виктория белән берлектә туплаган материал белән сезне Виктория үзе таныштырып китәр.

Виктория: Урта Кирмән авылыннан Фатыйхә һәм Фәттах Әхмәдиевларның өлкән улы Исмәгыйль яшь Совет хакимиятен яклап, гражданнар сугышында һәлак була. Бертуган энеләре *Мөктәсим, Мөхлисулла, Мәгъсүмҗан, Габделбарый, Мисбахетдин, Агмалетдин* абыйсының юлын кабатлыйлар. Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә үк барысы үз теләкләре белән фронтка китә. Алар Ватан-ананы яклап төрле фронтларда, төрле гаскәрләр составында көрәшәләр. Очучы Мисбахетдин легендар капитан Гастелло батырлыгын кабатлый. Әмма бер-бер артлы улларының һәлак булуы турында кара хәбәрләр килә. Фатыйх ага моңа түзми, бик иртә китеп бара. Ә Фатыйха апа могҗиза көтә: берсе исән калса да, кире кайтыр, дип өметен югалтмый. Менә бит кечкенә улы Агляметдин үзенең язулы фотосын җибәргән:

“...Иделләрне йөзәмен дә буйлыймын,
Киткән кошлар да бер кайта,
Кайтырмын, дип уйлыймын!”

Ул Ерак Көнчыгышта хезмәт итә, хатлар да Җиңү көненнән соң да килә. Әммә 1945 елның сентябрь ахырында элемтә өзелде…

Сугыштан күрше авылга кайткан Юнусов Мәгъсүм Агляметдиннең геройларча һәлак булуын (ул дошманның ут ноктасын күкрәге белән каплаган, Матросов батырлыгын кабатлый) һәм якын дустын күмгән вакытта шәхсән үзе катнашуын әйтә. Фатыйхә апаның соңгы өмете өзелә. Күздән соңгы күз яшләре агылды. Көч дә бетте. Ул гына да түгел 1946 елның 8 декабрендә вафат булды. Соңгы сулышы соңгы сүзләр белән үрелеп барды:

-*…Улларымны күрермен, дип өметләнгән идем... Кайталмадылар инде... Ләгънәт кенә төшсен инде бу йөзе кара сугышка, аны башлаучыларга!.. Минем кебек, чәчләре вакытсыз агарган аналарның... чиксез нәфрәте эзләп тапсын аларны! Эзләп тапсын... һәм без күргән-кичергәннәр өчен... үзләренә әз генә дә рәхәт күсәтмәсен!.. Аллаһы Тәгалә аларга тиешле җәзаларын бирсен!.. Ә сез... гөлкәйләрем... сау сәламәт булып... бәхетле-имин тормышта яшәгез!.. Миннән... хәер-фатиха сезгә!..*

Язучы Шахинур Мостафин тәкъдиме белән (скульптор Альфред Абдрашитов), 1997 елның 22 июнендә Мамадыш шәһәре үзәгендә Хәтер мәйданында Әниләр һәйкәле ачылды. Ак мәрмәрдән ясалган символик һәйкәл

Әхмәдиева Фатыйхә апага, шулай ук үз балаларын Ватан өчен сугыш кырларында югалткан барлык әниләргә багышланган

Сугышта сигез улын югалткан, әмма горурлык һәм түземлек, матурлык һәм батырлык саклаган ана безнең алда ак киемдә тора. Аның карашы, аның соңгы өмете булган кече улы Әгъләметдин калган көнчыгышка таба юнәлгән. Сул кулы белән йөрәккә, дошман пулялары белән теткәләнгән улының пилоткасын кыса – улларын үлемнән саклап калыр өчен сигез тапкыр үзе шушы пуляга барыр иде. Ә уң кулында - кыр чәчәкләре бәйләме – улларының каберләренә ничек кенә саласы иде!

Һәйкәл янында Фатыйхә апаның ялкынлы сүзләре алтын хәрефләр белән язылган: *“... Улларым сугыштан кайтмады,*

Кайтты тик “Көт!” – дигән хатлары...

Өзелеп көтәм мин һәр таңны

Улларым әйләнеп кайтканны!!!”

Шунда ук сигез улының җавабы:

“... Чыгар Кояш, сибәр нурын –

Бездән сәлам шул булыр...”

Укытучы: Бу очракта әйтер сүз дә юк. Фатыйхә апа сигез улын сугышта югалткан бердән-бер ана. Ана үзе дә, аның уллары да чын патриотлар.

Һәм без тагын бер Ана турында әзерләнгән идек. Бу Ана күрше Ямаш авылыннан. Бу турында сүзне Исламга бирәбез.

Ислам: Бөек хатын-кыз Мөгаллимә апа, көчле рухлы, олы йөрәкле, гаҗәеп кешелек сыйфатлары булган герой-ана, I, II, III дәрәҗә "Ана даны" орденнары белән бүләкләнгән. 1917 елда 18 яшьлек Мөгаллимә апа кулында дүрт бала белән калган 45 яшьлек Саттаров Габдрахманга кияүгә чыга. (өлкәненә-8 яшь, кечкенәсенә 1 яшь). Ел да яшәми, Мөгаллимә апа һәм Габдрахман абыйның беренче балалар үлә. 1921 елдан башлап бер-бер артлы тугыз бала дөньга килә. Мөгаллимә апа кыенлыклардан курыкмый: ире белән янәшә яшелчә бригадасында нык хезмәт куя, балалар үстерә, еллар буе гаиләдә татулык, игелек, тынычлык нигезе булып тора.

Саттаровларның өч улы: Мирхәйдәр, Әхәт, Әгъләм – Бөек Ватан сугышында катнашучылар. Өч уллары югары дәрәҗәдәге хәрбиләр: Мирхәйдәр – полковник, Габделхай – майор, хәрби хирург, Рафаэль – майор. Барлык балалар да лаеклы хезмәт юлын уздылар.

Укытучы: Ә хәзер, укучылар, минем сезнең Афган сугышына карата фикерләрегезне беләсем килә. Бу сугышта катнашкан яшь солдатлар патриотмы, алар бит читтә сугыштылар?

Укучылар:

- Патриотлар, алар бит приказ үтәделәр.

Укытучы: Афган сугышы турында сөйләшеп, фикерләшеп сүз бетәрлек түгел, бу турыда без аерым класс сәгатьләрендә сөйләшербез.

Укытучы: Ә бүген . тыныч тормышта патриот булып буламы?

Укучылар:

- Була.

Укытучы: Моның өчен нәрсә эшләргә кирәк соң?

- Армиядә яхшы итеп хезмәт итәргә
- Тырышып эшләргә.
- Туган илне яратырга
- Авылны яратырга
- Тырышып укырга

- Илне якларга кирәк булса, һәрвакыт әзер булырга

Укытучы: Мин Айгөлгә үз гайләләре турында кыскача гына сөйләргә тәкъдим иткән идем, тыңлап китик әле.

Айгөл:

Минем Тимерхан бабам һәм әбием Хәмидә әбием Фаляховлар Шәдче авылында беренче башлангыч мәктәп ачканнар һәм аның беренче укытучылары булганнар, минем Диншат әбием мәктәптә 35 ел эшләгән, минем әтием шушы ук мәктәптә укыта. Гомумән, безнең укытучылар династиясендә гомуми педагогик стажы 600 елдан артык булган 24 укытучы бар.

Тимерхан бабай чын педагог булган һәм ул тирә-юньдәгеләр арасында лаеклы абруй казанган. Авылдашлары аңа ышанганнар, аңа киңәшләшергә килгәннәр. Ул аларны яшәргә, коллектив хуҗалыгында эшләргә, ачлык елларында яшәргә өйрәткән. Дәүләт аның казанышларын лаеклы бәяләде. Ул Ленин ордены белән бүләкләнде, «РСФСРның Атказанган мәктәп укытучысы» исеменә лаек булды, «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде.

Диншат әбием 1944 елда Мамадыш педучилищесын тәмамлап, укытучы эшен башлап җибәрә. Башлангыч сыйныфларда да, математика, биология укыткан. Күп еллар ул мәктәп яны бакчасы җитәкчесе иде. Үз тәжрибәсе белән Мәскәүдә ВДНХ да мәктәп хуҗалыгы продукциясе күргәзмәсендә ике тапкыр катнашты. ТАССР Югары Советы Президиумының Мактау грамотасы, "Халык мәгарифе отличнигы» күкрәк билгесе, “Хезмәт ветераны” медале, "1941-1945 еллар Бөек Ватан сугышында фидакарь хезмәте өчен” медале белән бүләкләнгән.

Минем Фаляховлар һәм Камаловлар гаиләсенә караган якын туганнарым иң югары бүләкләргә: төрле дәрәҗәдәге 59 медаль һәм 14 төрле орденга лаек булдылар

Бөек Ватан сугышы чорындагы сугышчан орден һәм медальләрдән тыш, алар түбәндәге дәүләт бүләкләренә лаек булдылар:

- Ленин ордены -2 кеше;
- "Почет Билгесе" ордены -5 кеше;
- II дәрәҗә "Ана Даны" ордены -1 кеше;

- Петр I ның "Россия фәнен һәм икътисадын торгызу эшендә казанышлары өчен" алтын медале -1 кеше;

- "Яхшы уңышлар һәм үрнәк тәртип өчен" алтын медале - 6 кеше;

- Көмеш медаль - 6 кеше;

- 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында фидакарь хезмәте өчен. - 10 кеше;

- Хезмәт батырлыгы өчен -3 кеше;

- "Хезмәт ветераны" медале -13 кеше;

- "Халык мәгарифе отличнигы" билгесе -3 кеше.

Видео. Родина - это мы (социальный видеоролик про патриотизм к России)

(Фикер алышу)

а) бу яшь әни үзедә нәрсә эшләгәнен аңламый, баласын да начарлыкка өйрәтә

б) бу әни дә бернинди хисләр юк

в) узып баручы егет салкын карашлы

г) соңгы гайләне чын патриотлар дип әйтеп була

Укытучы: класс сәгате алдыннан мин сезгә мин сезгә укучылар арасында сорау үткәрергә тәкъдим иткән идем. Җаваплар белән танышып китик әле.

- сез үзегезне патриот дип саныйсызмы дигән сорауга укучыларның 72 проценты “әйе” җавап бирде

- Россиядә яшәвегез белән горурланасызмы? укучыларның 98 проценты “әйе” җавап бирде

- Россия офицеры һөнәре дәрәҗәлеме? (әйе - 75%)

-Үзегез, дусларыгыз өчен җаваплылык тоярга кирәкме ? (әйе-98%)

-сезнең үрнәк алырлык кешеләрегез бармы? (әйе - 75%)

Укытучы: нәтиҗә ясап шуны әйтәсе килә, димәк безнең укучылар үзләренең туган иле белән горурланалар, аны яраталар.

Укытучы: Безнең һәрберебезнең үзенең туган, үскән авылы, шәһәре, әти-әнисе, гайләсе, яшәгән йорты, белем алган мәктәбе, Туган иле белән горурланасы килә. Ә без илебез белән чыннан да горурланырга, аны яратырга, илебез өчен төрле батырлыкларга әзер булырга тиеш! Патриотизм-ул матур сүзләр генә түгел. Бу, барыннан да элек, Ватанга, илгә, үз халкына хезмәт итү. Бу хакта беркайчан да онытырга ярамый.

Укытучы: Ә бүгенге класс сәгатен Ариана башкаруында җыр белән тәмамлыйбыз.